КЛАРА БУЛАТОВА

# Дәнеү



КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2003

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Б76

**Булатова Клара**

Б76 Әрнү: Шигырьләр, поэма. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. — 159 б.

Җыентыкта соңгы елларда язылган әсәрләр туплап бирелә. Аларда шагыйрә кеше яшәешенең бөтен кичерешләрен ача, буыннар язмышының әрнүле кабатлануларын тормыштагы тирәнлеге белән күрсәтә.

ISBN 5-298-01341

© Татарстан китап нәшрияты, 2003

# I

# КОЯШ ИНДЕ КИТЕП БАРА ИДЕ



## Юл ачык та — еллар ябык

*(Елкы елында туган җыр)*

Кыш башыннан юл башладык.
Юл бозлавык, һава салкын.
Өшемәсме аяккаең,
Көмеш тояк Акбүз атым?

Армассыңмы, таймассыңмы?
Хәлсезләнеп калмассыңмы?
Сыгылмасмы ял-канатың,
Сорнай яллы Акбүз атым?

Кем кулында бүз тезгенең?
Уй-максатың ниләр өчен?
Кемгә тарта җегәр-көчең?
Нинди кеше чөңгерүчең?

Сукмаслармы тез астыңа?
Екмаслармы аяк чалып?
Чиктән чиккә ыргытылырга
Ярата ла безнең халык!..

Көтелмәгән тозакларга
Тармассыңмы ярсу барып?
Аумассыңмы, и, алданып —
Юл ачык та — еллар ябык.

Саф күңелле җанга әгәр
Күтәрешсәң хаклык хакын —
Юлларыңа ак җәймәләр,
Җыр канатлы Акбүз атым!

## Төс ташлады бу җир

Дулкынланам әле ни генә дип,
Яңа еллар җиргә кергәндә?
Яралы бит дөнья, әрнүле бит,
Хәвефле бит соңгы көннәрдә.

Карлары да быел ап-ак түгел,
Кар төсе дә керле, күгелҗем.
Кеше җаны кыйбла җуйгангамы,
Төс ташлады бугай ил-җирем.

Әче яшьләр күзнең нурын ала,
Җан сыкранып, әрнеп йөргәндә.
...Тик барыбер күңел дулкынлана,
Яңа еллар җиргә ингәндә.

## Үзгәлек

Әллә заман үзгәргәнгә,
Әллә язмыш көлгәнгә,
Бөтен нәрсә үзгәләнә,
Яңа елга кергәндә.

Әйтми: «Офицер булам», — дип,
Әйтми: «Шагыйрь булам», — дип,
Оныкның теле ачылды:
«Миллионер булам!» — дип.

Ни китерер экраннардан
Мигә күчкән бу уйлар?
Илне хәерчелек баса,
Өскә калка буржуйлар.

***

«Йә әле, җылын, — дисең, —
        кайнар чәй белән».
Чәең нәрсә? Анда урын җәелгән.
Аккош сурәтләре
Мендәр тышында.
Җан җылыныр урын
Менә шушында.
Ялгыз түгел Аккош,
Пары янында.
... Урыны җәюле,
Ашың табында.
Иң җылысы — назың,
Сине сөюең.
Җәннәт түгелдер дә —
Рәхәт үз өең.

***

Ник тәрәзә капкачларын
Көмеш бикләр чыңлата?
Ник бу кичләр яшерелгән
Сагышларны уята?
        Никләр, никләр көмеш бикләр
        Чың-чың килеп уята?
        Ник кузгата «кайтыр» дипләр,
        Кайтмый бит ул, еракта.
Кайта калса, аның өчен
Бикләр, чикләр юк бит ул.
Бу җиһанда аның урынын
Алыр читләр юк бит ул.

Көмеш бикләр, никләр, никләр
Мине болай үртисез?
Кайтсын гына, көмеш бикләр,
Ачылырсыз, кертерсез.

***

Без дә юкәдән түгел,
Артык иркәдән түгел,
Әмма яманнан түгел,
Төшеп калганнан түгел.

Йөрәк куш йөрәк түгел,
Мескен чүпрәк түгел.
Йон түгел, мамык түгел,
Гел тузган халык түгел.

Гел каты таш та түгел,
Иелгән баш та түгел.
Йөрмәбез көн үткәреп
Сөймәгәнгә сөйкәлеп.

***

Булмаганны!
«Сөйми башлады», — дип,
Ник сөйлисең юкны?
Кит әле!
Сөйми башлар өчен, башта сине
Яратырга кирәк бит әле.

***

Тынгысызлый нигә һаман шулай
Карашларың синең?
Мин акылдан язып барам бугай.
(Андый түгел идем!)

Әллә кая дәшә, әйди бу ай
Тавыш-тынсыз гына.
Мин акылдан язып барам бугай —
Син канәгать шуңа!

Бу мавыгу (күрсәтмәсен Ходай)
Болай гына үтмәс.
Мин акылдан язып барам бугай,
Шушы яшькә җиткәч.

Юк, кирәкми! Юк, карама шулай,
Ышандыра күрмә!
Мин акылдан язып барам бугай
Синең белән бергә.

Көн кичермәс безне, илдә шулай
Ике юләр артса.
...Без акылдан чынлап яздык бугай —
Акыл керер чакта.

***

Ә мин әле һаман сине көтәм,
Әле һаман өмет-өн яши.
Хыял җебен мең кат урыйм, сүтәм,
Йөрәк гөжли, акыл эндәшми.

***

Тезгә түнми тора гәүдәм генә,
Тыштан гына горур башым да.
Ә чынлыкта инде мин-минлегем
Әллә кайчан аяк астында.

Телем генә сөйли тискәре сүз,
Каршылыгы сынган уемның.
Чынлыкта бит инде мин бәхетсез
Әллә кайчан синең колыңмын.

***

Бернәрсә дә юктан тормый,
Тәңкәләнми су җилсез.
Омтылышсыз очу булмый,
Яшьлек булмый сөюсез.

Бернәрсә дә юктан булмый,
Шытым үсә орлыктан.
Күңел үсә җылы сүздән,
Күңел төшә шул юктан.

Бернәрсә дә юкка чыкмый,
Кояш бата, нур кала.
Күңел үсә, күңел төшә,
Сөю кала, җыр кала.

***

Бер нәрсәдән курка күңел
Бу имансыз дөньяда:
Явызлыкка кирәк түгел
Тәһарәт тә, намаз да.

Яхшылыктан ни туганны
Күргән юк та юклыкка.
Яманлыктан яманлыгы
Туып тора бу йортта.

Яшьләр өчен үрнәк булыр
Өлкән буын дигәне.
Ни нәрсәгә өйрәтә соң
Үзеннән соң килгәне?

Аккош идек, күлдә йөздек,
Күккә мендек җыр булып.
Аккошлыкны җиргә күмдек,
Күселеккә юлыгып.

Бер хакыйкать, кабат-кабат
Шуны искә төшерәм:
Аккоштан да күсе туа,
Аккош тумый күседән.

Явызлыкка явызларча
Каршы торыр заманда
Кирәк түгел тәһарәт тә,
Кирәк түгел намаз да.

Тик сыкранып тыпырчына,
Аккош чагын сагына.
Иманыннан мәхрүм калган,
Төпкә төшкән җан гына.

***

Тынлыгы белән шомлы төн,
Тавыш та юк шылт иткән.
Шул чагында тып-тын гына
Берәү керде ишектән.

Рөхсәт-мазар сорамады,
Шакып-нитеп тормады.
Тик күренде шәүләсенең
Өй түренә узганы.

Читләр-ятлар йөрми монда,
Димәк — Үзе! Ул кайткан!
...Юк икән шул. Кайтмаганы
Таң йокымнан уяткан.

***

Бер ай гына йөреп калдык,
Армиягә озаттым.
Бер генә ай көтеп алдым —
Бер айдан соң син кайттың.

Әмма сине кайтардылар
Табут белән таулардан.
Бер генә ай йөреп калдык —
Минем чәчем агарган.

Яшь гомерләр ник юлыкты
Каһәренә Алланың.
Ник, ичмасам, сөйгәнемнән
Бала белән калмадым?

Җирләсәк тә табутыңны
Үзебезнең зиратка.
Син монда дип ышана алмыйм —
Җаның чыкты еракта.

Соң сулышың киселгәндә,
Бәлки, син дә иң элек
«Әни»дән соң исемемне
Әйткәнсеңдер өзелеп.

Киләм дә мин кабереңә,
Озак торам югалып.
Йөрәк тына, тын буыла
Җепселләргә уралып.

Чәч агартыр афәт инде,
Тереме мин, үлеме?
Тумас борын кем үтерде
Безнең керсез сөюне?

***

Син үлчәүсез мескенлектә бүген,
Котылыр юл синең өчен юк.
Күңелеңдәге изге ниятләрне
Көнгә ашырырлык көчең юк.

Тик йөрәге ярлы тәкәбберләрнең,
Таный алмый шушы чынлыкны.
Кире каккан булып, и бичара,
Күпме югалтуга юлыкты!

Бурыч яшергәннәр бөлә бит ул,
Үлә бит ул чирен яшергән.

...Изге ниятләрең көнгә ашмый
Сугарасың да җирне яшь белән.

Мескенлегең инде битлегеңнән
Бәреп чыкты. Хаклык әйтәдер:
«Иелгәнне генә кылыч кисми», —
И башыңны, ярлы тәкәббер!..

***

Үләсе калган яшь килеш,
Исемнәр тапланганчы.
Көндәшләр кара көйгәнче,
Сөйгәннәр ташлаганчы.

Кичергән хистән, сагыштан
Күз төбе күгәргәнче.
Акылсыз гомер итте, дип,
Дошманнар сөйләгәнче.

Үләсе калган яшь көйләй,
Чигәләр агарганчы.
Гөнаһка батып яши, дип,
Яманат таралганчы.

Маңгайдан ияккә кадәр
Җыерчык каплаганчы.
Дөньяның тупас итеге
Җаныңны таптаганчы.

Булмады үлеп яшь көйләй,
Җазыкка кумелгәнче.
Җандагы кара яралар
Галәмгә күренгәнче.

Йомарлам керсез йөрәгем
Күгәреп какланганчы.
Ә хәзер... яшәргә кирәк
Яшәвем акланганчы!

***

Кояш инде китеп бара иде,
Әллә нинди суык җил өреп.
Афәт булып гөлбакчамда йөреп,
Чәчәкләрне китте шиндереп.

Куырылып сулган куакларны
Терелтердәй өмет калмаган.
«Ни гөнаһым өчен бу җәза?» — дип,
Инәлепләр сорыйм Алладан.

И могҗиза! Иртән торуыма
Түтәлләрем кабат яшәргән.
Шифа алып мине кызганудан,
Фәрештәләр түккән яшьләрдән.

## 1999

Бер берлек тә өч тугызлык,
Гел берлектә ел уздырдык.
Татулык дип тел туздырдык,
Ә чынлыкта ил туздырдык.
Тузган илдә ни тудырыр
Бер берлек тә өч тугызлык?

Яңа елда яңа бәхет,
Кемгә киндер, кемгә бәрхет,
Кемгә капкын, кемгә тәхет.
Кемнәргәдер таш тигердек,
Кемнәргәдер таҗ кигердек.
Юк гаделлек, юк тигезлек.
Ая, дөнья! Ни кыдырдык?
Эчтән өреп, җил тудырдык,
Бәйге кордык, койрык бордык,
«Ләббәйкә» дип карап тордык,
Инде хәзер аек булыйк.
Бер берлек тә өч тугызлык.
Мәмләкәттә хәрәкәтне,
Хәрәкәттә бәрәкәтне
Саклый алыр ил торгызыйк.
Сафта торыр хак тыгызлык.
Бер җан, бер тән милләт булыйк.
Ипле керсен, имин килсен,
Халык көткән хаклык бирсен
Мең тугыз йөз туксан тугыз!

***

Синнән соң да, әни, ун ел үткән,
Яңа еллар килгән дөньяга.
Синнән соң да күпме хезмәт иткән:
Синең мирасыңны иҗат иткән,
Кешеләргә илткән бу бала.

Әле тагын күпме гомер бардыр —
Аны белә бары бер Ходай.
Синең рухны, әнкәй, рәнҗетмичә,
Синең сүздән читләргә китмичә
Яшәп булса иде гел шулай.

***

Тирән иде хыял дәрьяларым,
Күңел офыклары киң иде.
Кемнәр аны шулай саегайтты?
Кем тарайтты? Кем күз тигерде?

Тирән иде хыял дәрьялары,
Йөзәм диеп кердем упкынга.
Ниләр сәбәп булды батуыма?
Кемнәр тартты төпсез упкынга?

Киңнәр иде күңел офыкларым,
Офыкларга томан уралды.
Ни каерды үсеш канатларын?
Кем бәйләде каурый кулларны?

Каурыйларым җилгә сибелде дә
Өметсезлек басты күңелне.
Тирән иде юкса өмет дәрьям,
Күңел офыкларым киң иде.

***

Минем һаман яратасым килә,
Яратасым, яраттырасым.
Синең белән төннәр үткәрәсем,
Синең белән таң аттырасым.

Куеныңа сыенасым килә,
Иңнәреңнән килә үбәсем.
Үзеңнән дә сөйдерәсем килә —
Яшәп булмый шунсыз, күрәсең.

Чәчләремне туздырасым килә,
Туздырасым, тараттырасым.
Минем һаман яратасым килә,
Килә һаман ярattырасым.

***

Тәнәкә — Шагыйрь җанының
Үз көе булган икән.
Җирдәме, күктәме туган
Чын сөю булган икән.

Табигатьнең Ул яратыр
Баласы булган икән.
Йөрәгенең җыр тудырыр
Ярасы булган икән.

Каләменең шигырь язар
Карасы булган икән.
Үзеннән соң Дастан булып
Каласы булган икән.

...Сер булып кала алмаган
Төене булган икән.
Тәнәкә — Олы Шагыйрьнең
Сөюе булган икән.

***

Тышта ап-ак кар ява,
Тәрәзәләр бозлана.
Тәрәзәләр бозлана,
Күңел тынгысызлана.

Юктыр кебек сәбәп тә,
Ник иртәнге сәгатьтә
Җан-йөрәгем сызлана?
Күңел тынгысызлана.

Тышта ап-ак кар ява,
Ак бөркүләр юлларда.
Ак бөркәүне кушалар
Хәерлегә юрарга.

Балаларым юлларда,
Хәерле юллар булсын.
Кердек яңа елларга,
Хәерле еллар булсын!
Хәерле еллар булсын!
Хәерле еллар!

***

Үз шигырен үзе укый икән,
Ничек тели — шулай укырга
Хакы бар бит аның!
Сүзләренә
Үзе хуҗа бары ул гына.

Актер түгел, Автор сезнең алда!
Һәм сез шулай кабул күрегез,
Сәнгатьле сүз остасы дип түгел,
Шигыренә бәя бирегез.

Бәяләгән чакта үзегезне
Тикшерегез ләкин иң элек:
Шигырьләрне бәяләрлек булып
Җиттегезме икән өлгереп?

***

Сәясәтче дә түгел мин,
Сәяхәтче дә түгел.
Бер әләкче дә түгел мин
Һәм гайбәтче дә түгел.

Адашкан җан да түгел мин,
Саташкан җан да түгел
Һәм шуларның берсеннән дә
Чын азаттан да түгел.

***

Унҗиденче гыйнвар.
Ни хәлләр бар
Бу көннәрдә фани дөньяда?
Илдә-көндә дәүләт белән бергә
Деннәр яна, иман югала.

Милләт чире, мөлек-мөлкәт чире,
Тән чирләре җанны теткәндә,
Адәми зат чыгар юл табармы,
Бар гаепне эзләп үткәндә?

Героиннар чиста сыйфатлы да,
Саулыгыңа зарар ничаклы!
Артын-алдын уйлый аламыни
Сәрхуш гарип җаны беркатлы.

Рәсәй аша наркотиклар китә
Җир шарының төрле ягына.
Акча өчен җан-иманын сатар
Кеше бездә җиңел табыла.

Ә нишләсен бәндә бүген көндә
Эшсез, көчсез, денсез, кыйбласыз?! —
Бу сорауга минем җавабым юк...
Сез үзегез, бәлки, уйларсыз?!.

***

*(Җиңел саллы җыр)*

Ходай сине минем өчен җиргә китергән,
Ходай сине минем өчен хаслап үстергән.
Ходай сине миңа кадәр ялгыз иттергән,
Ходай мине сиңа кадәр ялгыз иттергән.
Синең белән парлы итте, Аллага шөкер!

Тәкъдир сине еракларда йөртә кай ара,
Алларыңа ятлар куеп, шайтан шаяра.
Кайчакларда утка салып януымны кичер,
Кайчакларда ут атасың — алуымны кичер.
Ятлар кала — син кайтасың, Аллага шөкер!

Тәкъдир безне гел сынаулар алдында тота,
Җан-күңелне уттан ала, суга ыргыта.
Яраткан җан гына шулай янып көнләшә,
Яна-көнли бергә яшик соңгы көнгәчә.
Яраткан җан утка керер, суга да төшәр.
Яратышып үтә гомер, Аллага шөкер!

***

Тәңре кушуын тыңлыйм, каршы дәшмим.
Бу гөнаһлы җирдә әле тагын
Белеп яшим, тынып көтеп яшим
Кайчан да бер күрешәсе барын.

Бу гөнаһлы җирдә әле тагын
Күрешү барын белү яшәтә дә.
Кайчанлыгын белсәм барыр идем,
Йөгерер идем белсәм кайдалыгын,
Таш яуса да, яшен яшьнәсә дә.

***

Интектерә, белмим, нидер,
Ниндидер бер чир инде.
Әллә бавыр, әллә бөер,
Әллә бүтән җир инде.

Вакыт та юк, акча да юк,
Докторга барыр өчен.
Берөзлексез иртә-кичен
Бора да бора эчем.

Әллә үләм ике көннән,
Әллә үләм бер айдан.
Ярдәм көтмим һичбер кайдан,
Үлем көтәм Ходайдан.

Бүген түрдәге түрәләр
Безнең хәлгә кирәме?
Пенсионер карчыкларның
Беткән инде кирәге.

Кемнән ни ярдәм аласың?
Телим бары үземә:
Ятырга гына язмасын
Карап кеше күзенә.

***

Августның да ундүрте бит инде,
Болыннарга көз билгесе инде.
Җәй чигенә килә, чигенә,
Шул җәйләрне, әй, тоткарлар өчен,
Җимешләрен җыяр, барлар өчен,
Бирмәс идем бүген ни генә!
Тып-тын гына көзләр керер инде,

Быел көзләр ниләр бирер инде
Юлын җуйган таркау илләргә?
«Сабырлыклар сары алтын», — диеп,
Ят алдында һаман башын иеп,
Яшәр халкым тарыр ниләргә?
Августның да ундүрте бит инде,

Ундүрт саны хәерле бер билге —
Хәерлегә булсын барсы да.
Илләр-җирләр имин генә торсын,
Җыйган уңыш үзебезгә булсын,
Исән керик яңа гасырга.

***

Унбиш минутта ни эшләп була?
Унбиш минутта күп эшләп була:
Сүзләшеп була, телләшеп була,
Эндәшеп була, тел тешләп була.

Унбиш минуттан күп алып була,
Телләшәм дисәң, сүз табып була.
Акыллы булсаң, — телеңне тешләп,
Эндәшми генә тын калып була.

Унбиш минутта каршы ягыңның
Үткәнен телдә чайкарга була.
Ата-анасын, әби-бабасын,
Кабер тактасын тапларга була.

Унбиш минутта кереп тә утка
Янмый да чыга алырга була.
Сабырың җитсә —
        үз дәрәҗәңне
Дәшми дә саклап калырга була.

***

Камышлар шуылдаша да
Еланнар ыжылдаша,
Илләргә яман хәбәрең
Тарала шулар аша.

...Каеннар лепердәшә дә,
Юкәләр ипле дәшә.
Каеннар кебек чиста бул,
Юкәдәй ипле яшә.

***

Бу елда соңга калган көзнең
Әле әллә ничә язы бардыр:
Ничә тапкыр кары ятып эрер,
Ничә кабат явып китәр яңгыр.

Ничәнче кат уҗым бәскә төренер
Һәм яшәрер ничә мәртәбә.
Әле күпме язны кабатлагач,
Керсә керер бу көз тәртәгә.

Менә шунда инде, китеп беткәч
Сыерчыклар, кара каргалар,
Үзебезнең дуслар — кышкы кошлар
Бураннарны дәшеп сайрарлар.

***

Кошлар монда әле, күченмәгән,
Әмма алар инде сайрамыйлар.
Тик эш белән генә, йомыш белән
Бер-берсенә дәшеп алгалыйлар.

Юл хәстәрен күрә сандугачлар,
Төенчеген төйнәп куйган тургай.
— Син быел да монда каласыңмы? —
Дип, чыпчыктан чәүкә сорый бугай.

***

Әгәр ирең: «Мин кабергә кадәр
Сиңа тугры!» — дисә, —
алдый ул!
Булдыра алса, шул кабердә генә
Тугрылыклы булып калыр ул.

***

Хәзер кайда эшләсәң дә,
Тормыш тоташ бер «ямь»дер.
Атнасына алты ял да
Җиденчесе бәйрәмдер.

Бәйрәм итеп яшәгәнгә,
Аек башлар әзләрдер.
Гел сәрхушкә күчкән дөнья,
Белмим, нигә әйләнер...

***

Сусаганда, кое казы,
Туңсаң әгәр — мичкә як.
Карының ачса, ипи пешер,
Ялгыз калсаң — төренеп ят.

Килерләр, ялгыз итмәсләр:
Утың, суың күренер.
Кем җылыңа, кем суыңа,
Кем ипигә кулын сузар,
Кем... үзеңә үрелер.

***

Кайсы әйткән: «Әче дөреслекләр
Яхшырак, — дип, — татлы ялганнан»?
Юк, кирәкми миңа ул дөреслек,
Җаным кысыла минем аңардан.

Юк, кирәкми, әйтә күрмә миңа
«Сөймим сине» дигән сүзеңне.
«Ярата» дип (фал дисбесе тартып)
Ышандырып яшим үземне.

Шулай диген син дә,
«Сөймим» димә!..
Шундый җиңел мине алдарга.
Үзем телим ләса алдавыңны,
Мин бит күптән әзер аңарга.

***

Сусыз, күлсез иде безнең яклар,
Йөзә белми үтте балачаклар.
Хыяллар да башка булыр иде,
Күреп үскән булсак акчарлаклар.

Үскәч кенә йөрдек төрле якта,
Балтикада, Кавказ йә Карпатта.
Җырлар яздык юлда йөргән чакта,
Җырлар яздык атап туган якка.

Ә туган як — ул диңгезсез иде,
Кыр-басулар диңгездәй киң иде.
Кайда гына йөрмик — шул якларда
Сагынуыбыз диңгезгә тиң иде.

Диңгезләрдә гөжли акчарлаклар,
Бездә гөрли әнә күгәрченнәр.
Акчарлаклар күчкән җирдәгеләр
Безнең яктан әле көнләшерләр.

***

Тәрәзәдә беренче боз бизәк.
Нидер көтеп уянды бу йөрәк,
Нидер туар, димәк, бу кышта.
Һәр аклыкны гел шатлыкка юрап,
Һәр мизгелдән гел изгелек сорап,
Гел алданып яшим тормышта.
Көзләр бетеп, кышлар җитеп бара,
Соңгы көнгә якыная ара,
Һәр фасыл — бер адым картлыкка.

Тәрәзәндә беренче боз бизәк.
Һәм син, шуны терелтергә теләп,
Бизәкләрне тере гөлгә тиңләп,
Бүген тагын шигырь язмакчы? —
Гомер бакый инде шулай килгән,
Җан-йөрәкне изге ялган белән
Дәвалаган шагыйрь-алдакчы.
Ул бүген дә әле туң бизәктән
Ни нәрсәдер табып алмакчы,
...Тәрәзәдә югыйсә боз бизәк.

***

Өзелмәс тә өзмәс бер моң килә,
Ияреп килә ерак язлардан.
Яшьлек җыры яши йөрәкләрдә,
Кайтмаса да үзе яңадан.

Өзелмәс тә өзмәс бер моң килә,
Ияреп килә әллә кайлардан.
Серле, моңлы хәбәр йөртә, гүя
Бер-берсенә... киткән ярлардан.

***

Бүгенге көн чуар. Артык чуар,
Чиста, якты түгел.
Дөрес анысы: җырга чүп-чар тутыру
Бер дә яхшы түгел.

Тик нишлисең? Тормыш чынбарлыгы
Минем каләмемдә.
Шигъри каләм нәрсә дип куансын
Илнең бу мәлендә?

***

...«Бәхет — хезмәт!» диеп яшәгәндә,
Алданганбыз, димәк.
Ул хезмәттән бәхет таба
Алмаганбыз, димәк!

Эшкә чумдык юкса бил—буыннар
Ныгыр-ныгымастан.
«Лаек ял»лык пенсиялек стаж
Инде баштан ашкан.

Пенсиясе ипи-сөткә җитми,
Шулмы «бәхет» безгә?
Гомер буе эшләп, «лаек ялга»
Җиткән көнебездә...

***

Бүтән килмә минем янымa син,
Куркыныч ут минем йөрәктә.
Сүнеп барган утка кагылма син,
Син яңадан аны көйрәтмә,
Син яңадан аны дөрләтмә.

Соңгы күмер инде, пыскып кына,
«Үләм, сүнәм» диеп торганда,
Син аңарга тимә, көлен өрмә,
Бүтән йөрмә безнең урамда.

Очкыннарны очырудан саклан,
Очкыннан бит ялкын кабына.
Ул ялкында үзең януың бар,
Бүтән килмә минем янымa,
Сүнеп барган утка кагылма,
кагылма!..

***

Менә шушы кара сазлар аша
Көмеш карлы кышлар якынлаша.
Бата-чума көзнең сазларына,
«Җәйгә кайтам», — диеп, җан талаша.

...Соңга калган әбиләр чуагында,
Ымсындырып җирне, көн алдаша.
Чалт аяз күк, дөнья үзгәрер күк —
Туар сыман гаҗәп бер тамаша.

***

Яфраклар очты, очты да
Туктадылар очудан.
Кар төшүдән башланмаган
Кыш башланды шушыннан.

Әллә нинди бер талчыгу
Изерәтә башны шулай.
Яшь үтүдән башланмаган
Картаю башы бугай.

***

*Америкада яшәүче татар шагыйрәсе Нурия Измайловага*

Сиңа унҗиде генә яшь,
Миңа инде утыз ике.
Икебез дә шәкерт шәрә,
Хыял бай, ул безнеке.
Икебез дә шигырь белән
Җенләнеп йөри идек.
Кайсыбыз кайсы язмышка
Иярәсен белми идек.
Мин инде соңгы курста,
Син беренчедә генә.
Мин «азау язган» талибә —
Укыйм бишлегә генә.
Син дә мәктәпне бишлегә
Тәмамлап медаль алган.
Уку йортлары билгене
Бик үлчәп куйган заман.
Кемнәрдер, төннәр утырып,
Хәрефләр ятлап алды.
Бишлене хәтта ул чакта
Кем нинди хакка салды.
Кемнәрдер, мөгаллимнәрнең
Ишеге төпләреннән
Китмичә, теләнеп алды, —
Ә безгә Ходай биргән
Хәтерле зиһен булышты.
Без, шөкер, ул бишлене
Тиешле булганга алдык,
Белемгә тиешлене.
Таратып башка җыйганны
Шушы уку йортында,
Яктыртыйм диеп дөньяны,

Мин киттем укытырга.
Син башка юлны сайладың,
Яшь идең, көчле идең.
Кысага сыя алмадың —
Һәм хаклы төсле идең.
Кысасын Татарстанның,
Тарлыгын татарларның
Хөр җаның кабул итмәде —
Уфага китеп бардың.
Башкортлар баскаклыгын да
Өнәми булды аңың.
Басылып анда калмадың —
Мәскәүгә китеп бардың.
Ә Мәскәү — Мәскәү инде ул.
Ирек сөйгән бикәгә
Тар булды Мәскәү — башкала,
Киттең Америкага.
Син хәзер анда яшисең,
Көмеш шәлең ябынып,
Көмештәй якты илеңне
Һәм телеңне сагынып.
Мин инде һаман шушында,
Укытам, дәрес бирәм.
Үземнең шушы шөгыльне
Илемә кирәк күрәм.

***

Ноябрьнең унҗидесе.
Күзге көннең төп билгесе —
Бераз гына җилләп ала,
Көн караңгы — чирләп ала.
404 нче бүлмә.
Студентлар.
Дәрес бара.
Хәсән Туфан. Махсус курс.
Ая, язмыш! Ак та Кара...

Алай гына булса икән?!
Ак-Карадан торса икән
Бу яшәеш, бу кичереш,
Шагыйрь үткән бу көнкүреш...

Шагыйрь язган шигырьләрне
Бу шәкертләр белерләрме?
Бүген Туфан иҗатына
Тулы бәя бирерләрме?

Кемгә чындыр, кемгә уен.
Кайсы дөрес? Атау кыен.
Җырга җыйган шагыйрь уен
Ватмый-түкми саклау кыен.

Бүгенге көн бүген сиңа
Шундый мөмкинлекне биргәч:
— Туфандагы Искәндәрне
Ил алдына чыгар! — дигәч, —

Ач телеңне, ач бигеңне:
Укы! Сөйлә! Ишетсеннәр —
Чын күңелдән сөя белгән
Чын Шагыйрьне бер күрсеннәр.

***

*Әлмәт көне өчен языльп та,*
*файдаланмый калган гөлләр шәлкеме.*

**Кереш**

Әлмәтебезнең туган көнендә
Бүлмә гөлләре бәйрәм түрендә.
Бу күргәзмәдә тел гөле белән
Өлешем керсен әле минем дә.
Бу шигырьләрем — телдән гөлләрем,
Туган көнеңә, Әлмәт, бүләгем.

**I**

Исле гөл.
«Тәрәзә төбем исле гөл,
Исерәм исләренә.
Сәгать саен, минут саен
Төшерәм исләремә,» — дип
Җырламаган кем генә!
Җәй дә, кыш та гел хуш истә
Яши исле гөл генә.

**II**

«Яраннар язгы гөл», — диләр,
Ә менә безнең якта
Яраннар өйләр түрендә
Ел буе чәчәк ата.

Өйдәге җылы сулыштан
Яшәүчән көчне алган
Ал, кызыл, алсу чәчәкле
Җырларга кергән яран.

## III

Ел буе яшел яшәгән
Кычыткан гөленең дә
Гөлләрне сөйгән бикәләр
Дәвалау серен белә.
Кына гөлем чәчәк атты,
Кычытканым, ат инде.
Күп абыйлар өйгә кайтты,
Әти, син дә кайт инде, дип
Җырладык балачакта.
Сугыш чоры балалары
Кычытканнар ярата...

## IV

Салкын тигән вакытта да,
Әрнесә дә йөрәгем,
Эч пошса да дәва була
Чәнечкеле гөлләрем.

Авыр чакта сөю көчең
Даруларга тиң инде.
Син үзең дә минем өчен
Чәнечкеле гөл инде.

## V

Кыш уртасында да, көзләрен дә
Күңелләрне язга гел дәшә.
Салкында да чәчәк коймый яши
Ал, шәмәхә, зәңгәр миләүшә.

## VI

Йорт кынасы, Бохар кыналары
Үзенә бер ямьле төс бирә.
Кыналарны шулай матур итеп
Әлмәтлеләр генә үстерә.

Шигырьләрдә, халык җырларында
Яшәп килә кына күптәннән.
Хәсән Туфан Әлмәт кыналарын
Җырларына тиккә кертмәгән!

«Син утырткан кына кайда монда,
Кайсы барак тәрәзәсендә?
Әлмәттәге барлык гөлләр аша
Искә төшеп йөдәтәсең лә,
Искә төшеп...»

## VII

Тәрәзәдән тәрәзәгә
Үрмәле үрмә гөлем.
Гөлләр кебек матур булсын,
Әлмәт, алдагы көнең.
Күргәзмәләр оештырып,
Бүлмә гөлләре белән,
Уңганнарың котлый сине
Туган көннәрең белән.

***

Яннарымда бары син барында
Җылы дөнья кышкы көндә дә,
Тар урамнар якты, киң авылда
Синең белән бергә йөргәндә.

Көннәр кыска еллар ахырында,
Әмма алар кыска булса да,
Һәр иртәсе җырлы елга тора,
Һәрбер киче җанга нур сала.

Җан терелтер язгы тамчы кебек
Кәрнизләрдә сөңге бозлар да,
Тирә-юнем балкып тора көлеп
Янәшәмдә, иркәм, син барга.

***

Җаннарыма кайчак кара кайгы куна,
Кайчакларда сары сагыш сыгылып тора.
Кара кайгы, салкын сагыш тулганда да
Үлми ул җан — мәңге тере — җырлап тора.

Җырларына кайдан шундый көч табадыр,
Көйләренә нинди сүнмәс хис саладыр.
Кайгы китә, сагыш үтә — югаладыр,
Җирдә шулар нигез булган җыр каладыр.

Тәхетлеләр тәхетендә бәхетледер,
Әмма алар вакытлыча тәхетледер.
Алар өчен тәхет җую — бәхетсезлек,
Җыр тудырган мәңгелеккә бәхетледер.

***

Акка күчерәсе нәрсәләр күп,
Язылa бит әле дәфтәргә.
Язылa бит! Ходай шагыйрь итеп
Яраткан шул нәрсә әйтсәң дә.

Кеше җаны җирдә ни кичерә,
Нинди уйлар йөртә күңелендә,
Нинди борчу йөри башларында,
Ниләр бара бүген Илемдә —
Шулар бар да шушы дәфтәремдә,
Каләмемнән калмый берсе дә.
Яшәсәм дә мәҗрук бу хәлемдә
Шагыйрьлегем шагыйрь көчендә.
Гомер генә менә үтеп бара,
Китеп бара, кими — өстәлми.
Үткәннәргә түгел, әле алга
Юнәлтәсе иде көчләрне.
——————————
Айның әле ике атнасы бар,
Елның әле тагын ае бар.
Насыйп булса, минем башланмаган
Унҗиде ел гомерем тагын бар.

***

Болыннарда нур булганда,
Шат күңелле күбәләк...
Күбәләкле болыннарда
Йөри идек бергәләп.

Син дә, мин дә шат идек шул,
Бик күңелле чак иде,
Бик күңелле чаклар иде,
Икебез дә шат иде.

...Болыннарда нур сүнгәнгә
Моңсуланган гөлләр дә.
Моңсу гөлле болыннарга
Чыкма көзге көннәрдә.

Син дә, мин дә шат түгел бит,
Сөенеп йөрер чак түгел.
Сөенеп йөрер чак түгел шул:
Ярын җуйган саф күңел.

Гөлләр сулган болыннарга
Карлар төшәр көн җиткән.
Мәхәббәтен саклый алмый,
Кемне ташлап кем киткән?

Кемнәр ятка юлыккан да
Үз сөйгәнен оныткан?
...Ярын ташлап, ятны башлап,
Кем бәхеткә юлыккан?

***

Ботакны сарган сыкылар
Алмаш җәй чыкларына.
Туңган җимешләр татлы нан
Миләш чыпчыкларына.

Янәшә, парлап кунганнар
Кар төшкән чыршыларга.
Салкыннан курыкмый алар —
Әзерләр кыш чыгарга.

Илаһи кышкы матурлык
Тын урман уртасында.
Сокланып торам,
...һәм торып
Каласым килә шунда.

## *Яңа елга керәм, дигәндә...*

Ап-ак шәлләр ябып иңнәргә,
Яңа елга керәм, дигәндә,
Яшьле пәрдә тартып күзләргә,
Яман җилләр йөри илләрдә,
Яман җилләр йөри илләрдә.
Мең тугыз йөз туксан тугызның
Соңгы ае үтә — декабрь.
Соңгы айның соңгы көннәре
Тарих төпкеленә китәдер.
Ни теләсәң нәрсә үтәлер —
Яңа гасыр башы җитәдер.
Яңа гасыр башы җитәдер,
Яңа гасыр туып килгәндә,

Инде тагын ниләр көтәдер
Бу иманын җуйган илләрдә?
Ниләр булыр килер көннәрдә,
Яңа гасыр туып килгәндә?
Гасыр башы, гасыр азагы
Дәҗҗалларның хәтәр азавы,
Шомландыргыч сугыш авазы —
Бу адәмнәр шуңа азамы?
Гасыр башы, гасыр азагы...
Үз илендә үзе яу корып,
Үз кешесен үзе аттырып,
Калаларны күктән ваттырып
Утырганны нишләп тоттыгыз?
Җимерелде, черде, таралды
«Бөек Рәсәй» дигән йортыбыз —
Җирдә синнән нинди дан калды
Тезелепләр дә баскан өч тугыз?
Шушы сүзләр йөри тирәдә
Ак юлларга салып күләгә,
Кара сөрмә ягып күзләргә...
Ап-ак шәлләр ябып иңнәргә,
Яңа елга керәм, дигәндә.

***

Гыйльмениса карчык шәлләр бәйли,
Юк, зур керем көтми дә әллә ни —
Бәйләм шәлне хәзер алмыйлар,
«Базар тулы импорт шәл!» — диләр.

Бәйли иде элегрәк әле
Оекбашлар, җылы башмаклар.
Алары да хәзер үтмәс инде
Базар тулы әнә «качаклар».

Ялтыр башмак сатып утыралар,
Күз яуларын ала торганын.
Тик өч көн дә кими, табаннары
Кубып төшеп кала торганын.

«Импорт» диеп, авыз суы кибеп
Йөри инде безнең бу халык.
Үз җиренең әҗерен-кадерен белми,
Бар дөньясы бетте буталып.

***

Яңа елда кайдадыр
Яңа җаннар яралыр.
Яңа елда кайдадыр
Газраиллар җан алыр —
Шуны тою, һай, авыр...

Яңа елда бәхет көтеп,
Күпме күңел алданыр!
Их! Беркатлы ышанычлы
Яңа еллар кайдадыр?..
Өметсезлек, һай, авыр,
Авыр!..

***

Алтын арыш басуын
Мөнбәр итеп басуың
Җир кадерен белмәгәннең
Китерәдер ачуын.

Арыш кыры турында
Беркатлы саф җырында
Сыңар сүз дә әйтмисең бит
Шул «бөек зат» турында.

Биектәге ул түрә
Нәкъ менә шуңа күрә
Синең бөтен иҗатыңны
Танымый, түбән күрә.

Җир кадерен белмәстер,
Җир җырчысын сөймәстер.
Ниләр генә сөйләсә дә,
Җырларыңа кермәстер.

Һәм аларны инкарьләве
Уты үтмәс яшендер.
Алтын арыш басуларын
Мөнбәр итеп яши бир!

***

Мин бу җирдә озак яши алмам,
Бу гомернең язы санаулы.
Быел миңа күктән бар йолдызлар
Чакыру күзе белән карады.

Яктылык бит аннан озак килгән —
Шунысы өмет бирә йөрәккә!
Мин җавапны тавыш белән бирәм —
Ә ул озак йөри бигрәк тә.

Шулай булгач, кемдер көенергә,
Кемдер сөенергә ашыгып
Ялгышуы мөмкин. Үзем исә
Яшим әле ташка баш орып.

Беләм юкса күпме орышсак та,
Таш ярылмас — башым ярылыр.
«Шул кирәк!» — дип, кемдер шатланса да,
«Иртәрәк...» — дип, күпләр кайгырыр.

Мин кешеләр өчен яндым һаман,
Халык үзенеке санады.
Тик барыбер китми кала алмам,
Бу гомернең язы санаулы...

Бел бәхет киләсен,
Бел аның китмәсен,
Тик миннән башласаң
Һәр көннең иртәсен.

Яңа ел кичендә
Икебез өчен дә
Куаныч табарбыз
Уртак йорт эчендә.

Яңа ел таңында
Син булсаң янымда,
Югалыр борчулар,
Югалыр бары да.

Яңа ел көнендә
Син булсаң өемдә,
Тынычлык, җылылык,
Нур яшәр түремдә.

Елларның юлы да
Яктырак тоела,
Янымда син булсаң
Бергә ел буена,
Гомерем буена,
Гомерләр буена.

***

Кемдер әлләниләр көтәдер дә
Яңа елда туар таңнардан,
Тик мин түгел, мин берни дә көтмим,
Алданудан куркам яңадан.

Әллә ниләр кемдер көтәдер дә
Яңа елда килер кичләрдән,
Тик мин түгел, мин көйрәдем инде
Ул алдаучан шашкын хисләрдән.

Кемдер әллә ниләр телидер дә —
Мин теләмим: байтак ялгыштым.
Мәңге үтәлмәгән теләкләрдән
Тәмам авыруга сабыштым.

Әле кемдер өмет йөртәдер дә
Яшьлегенә кире кайтырга.
Мин янулар, алданулар белән
Калам инде үткән гасырда.

***

*(Көндәлектән)*

Гасырның соңгы елында,
Аның соңгы көнендә,
Аның соңгы сәгатьләре
Үтә Нәдер өендә.

Нәфис китте кичтән эшкә:
«Кичтән кичкә кадәр», — дип.
«Килер елда күрешербез,
Исән кайтсам әгәр», — дип.

Ә мин калдым инәй белән:
«Калыйм инде калсам», — дип,
«Мин карамый кем карасын...
Исән кала алсам», — дип.

Мин үрмәләп идән юдым,
Инәй — өйнең түрендә.
Изге Рамазан аенда
Һәркем үз ролендә.

Мин инәйне мунча керттем,
Өс-башын алыштырдым.
Дүрт кызы да бар барын да...
Аларның һәркайсының

Яңа елда үз гамәле:
Кунакка барасы бар,
«Да! инде» дә «Во! инде» дип,
Бер ярты саласы бар.

Аларга уразаң ни дә,
Рамазаның ни тора!
Кайсы кайда ни кыладыр —
Инәй монда утыра.

Ә мин аны саклап ятам
Нәдер өе эчендә.
Гасырның соңгы елының
Соңгы көне кичендә.

Каенананы Яңа елга
Яңадан алып керәм,
Әллә ялгыш, әллә язмыш,
Әллә изге эш белән.

***

Яңа елга сәгать ярым,
Яннарымда түгел ярым,
Бу елда да бу бәйрәмне
Каршылыйбыз аерым-аерым.
Аерым-аерым кергән елда
Булырбызмы уртак юлда?

...Яңа елга тик бер сәгать,
Очрашмауга эше сәбәп,
Яңа еллар килер кич тә
Ташлый алмый шуны һич тә.
Һәркем көтә Яңа елны,
Ә ул саклый кышкы юлны.

Юллар берүк имин торсын,
Еллар берүк имин тусын.
Аерым-аерым кергән еллар
Бергә-бергә кавыштырсын.

Бергә-бергә үтәр еллар,
Бергә-бергә булса юллар,
Бергә-бергә булыр юллар,
Бергә-бергә булса уйлар.
Уртак булсын безнең уйлар,
Бергә булсын барыр юллар,
Аерым-аерым кергәндә дә,
Котлы булсын Яңа еллар,
Котлы булсын, котлы булсын,
Котлы булсын Яңа еллар!

***

Ай, авыр, авыр, авырта
*Шаян җырдан*

Һай, авыр, авыр, авырта,
Авырта йөрәккәем.
Нигә соң, әни, син миңа
«Яратма!» дип әйтмәдең?

Дөрес, син мине сакладың,
«Кичләрен йөрмә», — дидең,
«Егетләр белән күрешеп,
Алдана күрмә!» — дидең.

Йөремсәк булып үсмәдем,
Йөрмәдем, алданмадым.
Алай да, сәгате суккач,
Яратмый кала алмадым.

Ай, авыр, авыр, авырта,
Авырта йөрәккәем.
Нигә соң, әни, син миңа
«Яратма!» дип әйтмәдең?

***

Яшәгән чакта бу җирдә,
Җаным гел сезне сөяр.
Газиз миңа, бик үз миңа
Ләкеләр, Ләкелеләр.

Сугыштан соңгы елларда,
Ачлы-туклы чорларда
Кеше җаны җылылыгын
Күпме җыйдым мин анда!

Шул җылылар яктылыгы
Кайтарылса сүзләрдә,
Сәлам булып ирешелсен
Алар Ләкелеләргә.

Каләмем дә шуны теләр,
Телем дә шуны сөйләр.
Таза торсын, ару булсын,
Бай булсын Ләкелеләр.

Матур бәйрәм булып тусын
Һәр таң аткан көннәре.
Бәйрәмнәрдә бәйге тотсын
Үз керәшен көйләре:

«Ләкеләрдә җиде күпер,
Күпер саен бәкеләр»...
Үзе үстергән шагыйрәсен
Хәтерлиме Ләкеләр?

Ә мин, кайчан күзем йомылып
Бу тәнем гүргә иңәр —
Шунда гына, бәлки, сезне
Оныта алырмын, Ләкеләр!

## Бер хатирә

Олы көнне олы итә микән Ләке?
Бәйрәмнәрне ничек итә икән Ләке?
Гомер буйларына чыкмый уйларымнан
Күкәй тәгәрәтү Каран буйларыннан.

Уен коралыбыз
Бер уртак туп иде.

Отканда, Абайдан
Остасы юк иде.

Йә турыдан бәрә,
Йә кыйгачлап сала.
Тезгән кадәресен
Сыдыра да ала.

Әмма юмарт куллы,
Аны саран димә.
Откан күкәйләрен
Кире бүлеп бирә.

Бәләкәйләр һаман
Аның тирәсендә —
Ниһаять, туп күчә
Аннан берәрсенә.

Үзе китми һаман,
Дәрес биреп тора:
«Менә моннан үлчәп
Тәгәрәт!» — дип тора.

«Соң инде, — ди, — нигә
Башың кыңгыр салдың?
Куш күкәй отам дип,
Бер сыңарсыз калдың!»

Көлешәләр яшьләр,
Кызарыша кызлар,
Үртәшергә китсә,
Абайны кем узар?

Монда малайларның
Иң уйнагы бит ул.
Абай гына түгел,
Таз Иваны бит ул.

«Бала-чага күпме
Кукәй тәгәрәтте!
Ул уеннар синдә
Яши микән, Ләке?

***

Елак димәс мине белгән кеше,
Юләр көләчкә дә санамас.
Яшь аралаш көлеп гомер итәм,
Елап яшим көлке аралаш.

Каршылыкка бик еш юлыгам да,
Әйләним дип сирәк борылам.
Көчсез затны этеп төшерергә
Әзер торган ирләр юлыннан.

Әллә кая үрли алмасымны
Белгән хәлдә нишләп йөрергә?
...Ташка бәрмә, башың ватылыр, — дип,
Искәндәр юк киңәш бирергә.

***

Ерып чыга алмас болгавыр чор,
Ми саташа, күңел адаша.
Йөрәк кенә һаман: «Дөньяны җыр
Яктырта ала», — диеп маташа.

Йөрәк кенә һаман тыпырчына,
Мең җепселен өзеп канатып.
Явызлыкка җырлап каршы чыга
Бер коралсыз килеш җан атып.

***

Халык әйтсә, әйтер хагын
(Җырда дөрес сүз, димәк):
«Җырлаганда ят та ярый,
Елаганда, үз кирәк!»

Җырлап кына яшәп булмый,
Елар чак та буладыр...
Шул вакытта яннарыңда
Үз булмавы бик авыр.

«Ярның яты юк», — диләр дә...
Көндә төрле чак була:
Кайчакларда иргә хатын,
Хатынга ир ят була.

Җырлаучыга көй кирәк тә,
Җанга җылы сүз кирәк.
Җырласаң да, еласаң да,
Уйласаң да түз, йөрәк.

...«Җырлаганда, ят та ярый,
Елаганда, үз кирәк...»

Ничә көннәр язылмаган...
Июльнең бише инде.
Бер дә кулга алынмаган
Каләмең нишли инде?

Нишләсен, күгәреп ята,
Читләшеп үз эшеннән.
Бүген бит Шагыйрә апа
Яшелчәче ителгән.

Әнә мунча бакчасында
Алабута йолкый ул.
Яңгыр яумаган чагында,
Түтәлләрен утый ул.

Барысын үзе җитештерә —
Гел сатып аласы юк.
Кесәсендә акчасы юк,
Базарга барасы юк!

«Зыялы» дип аталсаң да,
Затын ничек тотасы?
Әнә көндезге ашына
Пешә борчак боткасы.

Бичара Шагыйрә апа,
Бичара Мөгаллимә!..
Ходай биргән сәләтеңне
Югалтмам җирдә, димә.
Бу хәерчелек биштәрен
Иңеңә элдең нигә?

...Белемең нигә кирәк тә,
Шигырең кемгә кирәк?
Ачыргаланып, ачынып,
Вакытсыз тынар йөрәк.

***

Ялгыш көндәлегем ачтым —
Чиста битләр күренде.
Бу дәфтәрдә язмый калган
Буш урыннар күп инде.

Мин бу йортта күпме көнне
Җир тырмашып уздырдым.
Җанда туган шигырьләрне
Телдән җилгә туздырдым.

Шагыйрә җан тәслим кылды.
Бу нигездә ни аңа?!
Тик барыбер юньле хатын
Тумады бу дөньяга.

...Ә бүген инде Питрау,
Аның икенче көне:
Бу утар булган утрауда
Карлыган пеште инде.

***

Ундүртенче июль көне,
Җәй уртасы җомгасы.
Кемнәрнеңдер юл ахыры,
Кемнәрнеңдер юл башы.

Кемдер килә, кемдер китә,
Кемдер тора тукталып.
Хәрәкәттә — бәрәкәт, дип
Чапканнарга туктау юк.

Бертуктаусыз юлда йөрим,
Бертуктаусыз гел чабам.
Бер туктасам, бетәрмен дип
Куркып торам туктаудан.

Кемдер башлый юллар башын,
Кемдер төйни ахырын.
Минем әле юл уртасы —
Тагын күпме тартырым?

***

Питрау атнасының шушы көннәрендә
Барасы иде урманына, үзәненә.
Җыясы иде мәтрүшкәләр белән бергә
Тәлгәш-тәлгәш пешкән каен җиләген дә.

Табигатьнең шул шифалы нәрсәләре
Тәнгә сихәт, җанга рәхәт бирер иде.
Заман кысып күшегешкән күңелләргә
Бер миһербан рухы, бәлки, керер иде.

Ярты гына көнгә ташлап торсаң иде
Бакчасын да... башкасын да Нәдерендә.
Кыңгыраулар, ромашкалар җыеп кайтып
Салсаң иде илтеп әни каберенә.

***

Элекке хәтерең тунган,
Тузган, таушалган, туган!
Шуңа бүтән бер чараң юк
Теркәп, язып куюдан.
Ә син каләм дә алмыйсың,
Үзең таркау булудан.

«Вакыт юк», — дип зарланасың,
Вакыт нигә булмасын?
Тик син аны дөрес итеп
Файдаланмый куасың:
Ни чуртыма, Каләм ташлап,
Көрәк тоткан буласың?

Синең аңа көчең җитми,
Кулың ятмый аңарга.
Казынасың — эшең бетми,
Вакыт калмый язарга.

Күпме мөмкин, исраф итеп
Ходай биргән сәләтне,
Зиһенеңне җилгә җилпеп
Әрәм итү бу хәтле?!

Башың бар да — акылың юк,
Мәңге яши белмисең.
Үз-үзеңне бәясезләп,
Нигә болай йөрисең?

Син дә мәңгелек түгел бит,
Язмыш чиге бер инде:
Әзме-күпме гомерең булса,
Хет шул калган кадәресен
Иҗатыңа бир инде!

***

Ә бу дөнья инде кая бара?
Өмет сүнеп куя кай ара:
Хезмәт хакы кими, пенсия кими —
Товар бәяләре кабара.
Иске-москы киеп, мин, бичара,
Экраннарга чыгып утырам.
«Туган телем», «Иман, денем» диеп,
Нишләп йөргән булам, котырган.
Шигырьләрең, җырың кемгә кирәк?
Кемгә кирәк үзең, ниһаять?
...Әй, син нәрсә?
Тукта!
Тукта тизрәк!
Болай уйлау үзе җинаять.
Чаршавыңны бозып итәк тек тә,
(Беренчеме шулай эшлисең...)
Эзләп табып Әлмәттәге берәр
Телен белгән татар кешесен,
Төшереп кайт тагын «Җомга» өчен.
Тамашачы күрсен, аңласын.
«Дөнья бетә» дигән шомлы хәбәр
Күңеленә курку салмасын.
Эш барганда, дөнья бетми әле,
Тел дә исән әле без барда.
Татар рухы яңгырасын әле
«Җомга» көнгә биргән җырларда.

# II ФАНИ ДӨНЬЯДА ДА ИМАН КИРӘК



***

Мидә «зең-зең» шигъри кыллар зеңли
Җан-йөрәккә нидер бәрелүдән.
Илне-көнне нинди афәт иңли?
Сызып сыкрый күңел әрнүдән.

Бу дөньяның бөтен әрнүләре,
Зар-моңнары минем җанымда.
Минем аша үтә бар гамьнәре,
Барысы да миңа кагыла.

***

Еллар-сулар ага, ага, ага,
Дәрьяларга төшеп югала.
Дәрьяларда аккан сулардан да
Йөрәгемдә тирән моң кала.

Зәңгәр күктә Зөһрә йолдыз яна,
Таң алдыннан сүнеп югала.
Таңда сүнеп баткан йолдыздан да
Йөрәгемдә якты моң кала.

Елгаларга төшеп сулар алам,
Йолдызларга карап уйланам.
Туган җирем, мин бит бар гамеңне
Йөрәгенә җыйган бер балаң.

***

Бу йөрәк тынгылык ник белми соң?
Ник һаман уйлана, моңая?
Бу күңел, бу күңел ни эзли соң?
Бу күңел ник сыймый дөньяга?

Хыяллар омтылган рухи ирек
Табылмый ник кала тормышта?
Бу хәят, бу тормыш ник чикле соң?
Бу гомер, бу гомер ник кыска?!

***

Әвәләде дөнья кемне таштан,
Кемне комнан, кемне балчыктан.
Өлешенә тигән көмеше шул
Безнең буын өчен аз чыккан.

Булатлары ялтырасы чакта
Җиз сарысы өстә тирбәлде.
Терекөмеш тәгәрәде читкә,
Тимерләре иртә күгәрде.

Калыкса да, күтәрелә алмый
Югалалар башлык дигәннәр.
Дөньяларның кемгә мохтаҗ чагы?
Кайларда соң яңа Пәйгамбәр?

***

Аерылышты... уйлар,
юллар,
куллар,
Аерылудан, беләм, җаным сызлар...
Әмма сиңа иман кирәк түгел,
Миңа кирәк түгел имансызлар.

***

Җиденче кат күккә менәр кебек
И очына күңел, очына.
Әллә нинди дөнья көтә кебек
Ерактагы юллар очында.

Күк капусын хыял ачып куйган,
Күтәрел дә менеп җит кенә!
Әллә ниләр көтеп тора сыман
Күз күрмәгән дөнья читендә.

Биеклекләрдә зәңгәр һава төсе,
Хыялларда йөзеп чыгарлык...
«Берни дә юк анда» дигән төсле,
Итәгеннән тоткан чынбарлык.

***

Чыгарабыз диеп җирнең маен,
Җир күкрәге күпме тишелде!
...Зәңгәр газдан күкшелләнде каен,
Чахоткага тарган шикелле.

Керләнмичә кала алмаячагың
Бу якларда ачык бит инде.
Сафлык саклыйк дисәң, сеңлем, каен,
Берәр кая качып кит инде!..

...Кая качсын?!
Тауда җир уелсын,
Иңкүлектә упкын убылсын...
Адәм җаны кыйбла тапмас чакта,
Ул кайларга барып сыенсын?!

***

Яңача майның уртасы,
Искечә әле башы...
Бу гомердән тагын бер көн
Очты мәхшәргә каршы.

Тагын бер көнгә кыскарды
Гөнаһлы гомеребез.
Ахирәткә якынайдык,
Ә анда ни күрербез?

Мондагы фани тормышта
Күп газап чиккәннәргә
Ахири дөнья җәннәтен
Вәгъдә итсәләр дә,

Чындырмы анысы, юкмы —
Кем кайтып сөйләп биргән?!
Китәсе килми гөнаһлы,
Газаплы шушы җирдән.

Ел фасыллары чиратлый,
Ник шулай ашыгыла?
Яңача майның уртасы,
Искечә башы гына.

***

Ни булды соң әле сиңа, авыл?
Нидән сулды болай синең йөз?
Нигә шулай тоныкланып калдың?
Көннәр озын, кичләр күңелсез...

Кая китте кичке уеннарың,
Бүз егетләр, сылу кызларың?
Нигә алар сине ташладылар,
Ник аларга кирәк булмадың?

Җәйге озын көннәр кыска иде!
Сизми идек гомер узуны,
Ә эштән соң —таң балкышы гына
Булә иде кичке уенны.

Ник бүгенге авыл шундый тонык?
Сүлпәнлеге нидән? — билгесез...
...Кырда, юлда җырлар ишетелми,
Көннәр озын, кичләр күңелсез.

***

Җитмеш ел элгәре кебек,
Яңадан бәрдерикме
Күктәге гаделлек белән
Җирдәге гаделлекне?

Икесе алар чәкешкән
Җегәрдән туган чаткың,
Көйдереп кортыр тамырдан
Бу илнең нинди халкын?

«Без өстен, Галиҗәнап», — дип,
Ияген күккә чөеп.
Кем йөрер китап яндырып,
Көлләрен җиргә сибеп?

Андыйлар, әйе, табылыр,
Сантыйлар өер-өер!
Чүт шыта башлаган иман
Яңадан гүргә керер.

Тигезлек-хаклык билгесен
Куярга әле иртә
Күктәге гаделлек белән
Җирдәге гаделлеккә.

***

*Берәүгә*

Ниләр генә кылып яшәмәдең
Гел син диеп йөрсеннәр өчен,
Сине генә күтәрсеннәр өчен,
Сине генә күрсеннәр өчен.

Күтәрделәр, күккә күчерделәр,
Күпмеләрне этеп калдырып.
Вакытыннан иртә төшерделәр
Кабергә дә... бездән аерып.

***

Күпме генә яшәдем соң?
Күпме генә яшьнәдем?
Күпме генә сөйләсәм дә,
Әле берни әйтмәдем.

Күпме генә сөйләсәм дә,
Түгелсә дә сүзләрем.
Әйтәлмадым тик минеке —
Үземнеке дигәнем.

Ә әйтерем бар иде бит,
Әле ничек бар иде!
Әйтәм генә дигәнемдә,
Телем тешкә бәрелде.

Кабынганы дөрләмәде,
Пыскып калды учакта...
Үзәктәге шигырьләрем
Чыкмый калган китапта.

***

Әгәр тормыш сине алдый икән,
Ачуланма, каш та җыерма,
Йөрәгеңне учларыңа кысып
Тор да бертын упкын кырында,
Кушучыңны күкрәгеңә кысып,
Кире борыл яшәү ягына.
...Бу тормышта андый алданулар
Берни тормый яшәү алдында.

## *Туган җиремә*

Эзләп йөрим, табып,
кузләп йөрим
Гүзәллеген төрле җирләрнең.
Нинди гүзәллеккә
карасам да,
Сине күрә минем күзләрем.

Уйлап йөрим, ишетеп-
тыңлап йөрим
Төрле якның төрле моңнарын.
Нинди матур көйләр тыңласам да,
Сине ишетә күңел колагым.

***

Минем гомер минутларын
Бер-бер артлы кыра торган
Сәгать угын мин, бичара,
Тыя алмый карап торам.

Уйлый калсаң, бу фикер хак!
Өй эчендә бер дә юкка
Адым саен туган низаг
Бик охшый бит шушы укка.

Сәгать угын тыеп булмый,
Гомер юлын буып булмый,
Әмма аны кыскартуга
Юл куймаска була, була...

***

Гел былтыргы Яңа елдагыча,
Күбәләкләр булып, карлар оча,
Гел былтыргы Яңа елдагыча
Кергән бу ел былтыргыча узса,
Дөнья шулай киеренке торса,
Тормыш шулай киеренке торса,
Тормыш шулай гел тынгысыз булса,
Көн дә шулай хәвеф-хәтәр туса,
Яшәү гел шул куркынудан торса,
Һәр почмагы илнең учак булса,
Бәйләнышлар һаман чуалынса,
Ил соң нишләр һаман болай булса?
...Күбәләкләр булып, карлар оча,
Гел былтыргы Яңа елдагыча.

***

Тигез генә, туры гына түгел
Кылдан нечкә булган бу тормыш.
Асты-өсте килгән дөнья бүген,
Чакрым саен җиде борылыш.

Дилбегәләр кем кулында бүген,
Кем кулында бүген тезгенең?
Кем тоткарлый сикерешен көннең,
Үтәр булып заман тизлеген?

Минем аңнан сорау китми һаман,
Ә җавабын бирми бу тормыш.
... Юл чуалган, юл маяксыз калган,
Чакрым саен җиде борылыш.

***

Мин, мөгаен, татар хатыныдыр,
Бу турыда фикер йөрткәндә,
Бирә алмыйм хәер-фатыйхамны
Гаилә ташлап чыгып китkәнгә.
Ирләр китүгә дә риза түгел.
Ә хатыннар китәм диюгә,
«Ләббәйкә» дип, нинди
ана-күңел
Килә алсын шуңа күнүгә.
...Киңәш диеп озын вәгазь
көтмә,
Тик шул гына минем әйтер сүз:
Сабыйларны үксез-ятим итмә,
Үзеңне дә итмә бәхетсез.
«Бәхет башы — җәмәгатең», — диеп,
Борынгылар әйткән бик белеп...
Шул бәхетне үзе җимергәннең
Бар гомере үтәр үкенеп.

***

Биек-биек ызбада
Чигү чигә кыз бала.

*Халык җыры*

Ямь арттырып дөньяга,
Өйдә туды кыз бала.
Белмим, чигү чигәрме
Биек-биек ызбада?

Чигә иде әбкәсе,
Чигә белми әнкәсе...
Бәбкәсенең әнкәсенә
Килә шулай әйтәсе:

— Кызың туды — кыз булсын!
Тыңлаганы җыр булсын!
Бишек көйләп, иман өйрәт.
Соң булса да уң булсын.

Өйрәт шундый һөнәргә —
Тегәргә дә чигәргә,
Кыз балалар энә тотса,
Ямьнәр иңә өйләргә.

Бар бит туйлар буласы,
Бар бит халык йоласы.
Кызның кырык көненнән
Бирнә кирәк, диелгән.

Кодалар килер сорап.
Әйтмәгез: «Әле ерак!»
Гомер җилдәй үтә ул,
Бик тиз килеп җитә ул.

Шулай сөйли әбкәсе,
Тыңлар микән әнкәсе?
Әбкәсенең ак теләген
Үтәр микән бәбкәсе?..

***

Нинди нур ул? Нинди җыр ул
Күк читендә, офыкта?
Булмый сүзен өйрәнеп тә,
Булмый көен отып та.

Нинди яз бу? Нинди яр бу?
Нинди кош бу таллыкта?
Булмый үзен онытып та,
Булмый отып калып та.

Нинди кич бу? Нинди хис бу
Йөрәгемне җилкетә?
Булмый ташлап калдырып та,
Булмый алып китеп тә,
Булмый үзен ияртеп тә,
Булмый ташлап китеп тә...

***

Мин — шагыйрә,
мин шигырьләр язам.
Минем бакчам — шигъри түтәлләр,
Мин орлыклар гына чәчә алам,
Җыючылар булыр бүтәннәр.

Мин орлыклар гына чәчәм әле,
Чи җирлеккә, кәсле җирлеккә.
Җимешен дә килер җыяр мәле,
Ирешә алса халкым ireккә.

Мин кулыма утлы корал алмам,
Мылтык тотмам, тотмам кылыч та.
Мин — шагыйрә, мин тик җырлар язам,
Җир яшәсен өчен тынычта.

Тыныч илгә хас тигезлек белән
Яшәүләрне мәңге көткәннәр.
Мин шул өмет орлыкларын сибәм,
Өлгерешен җыяр бүтәннәр.

***

Кичтән чыгып, синең кайтыр
Юлларыңа карарга
Юк бит безнең өй өстендә
Күтәрелгән манара.

Киттең-баттың,
кайда нишләп
Йөрүләрең билгесез.
Күрер идем, белер идем —
Юк бит сихер көзгесе.

Дөреслекне белер идем:
Татлымы ул, ачымы?
Манара да, көзге дә юк,
Тәрәзәм дә ачылмый.

***

Кул салынган, хәрәкәтсез,
Хәрәкәте бәрәкәтсез,
Өй рәтсез, сүз рәтсез.
Нинди яшәү бер рәтсез.

Юк соклану, гаҗәпләнү,
Юк эзләнү, юк бер сорау.
Җанда нинди сәер хәл бу?
«Мәрткә китү», йокымсырау.

Ни нәрсә бу? Нинди хәл бу?
Кем эндәшер: «Йә, уян, тор!»
Күктән кътмә!
Китмә!
Чикмә!
Кузгалмасаң, кем уятыр?
Җиттек чиккә, әй, уян, тор!

***

Бу җырларда бернинди дә яңалык юк,
Көйләр шул ук, сүзләр шул ук кала әле,
Ә шулай да,
Ә шулай да,
Ә шулай да
Син аларга колак салып кара әле.

Бу күзләрдә бернинди дә серлелек юк,
Алар һаман шул ук коңгырт кара әле,
Ә шулай да,
Ә шулай да,
Ә шулай да
Син аларга бер тутырып кара әле.

Беләм, болар һич тә кирәк түгел,
Еллар үтмәс ерак безнең ара әле,
Ә шулай да,
Ә шулай да,
Ә шулай да
Шул араны юри үтеп кара әле.

Беләм, беләм, минем яшьлек, минем сөю
Үткәннәрдә...
Ә синеке алда әле,
Ә шулай да,
Ә шулай да,
Ә шулай да,
Аңлый алсаң, бу җанымны аңла әле.

***

Үзең теләгәнчә булсын әйдә!
Үзеңнеке — татлы гөнаһың.
Читлегеннән чыккан коштай җанны
Ничек тотып, ничек тыясың?

Ник тыясың аны?
                    Тоткын чакта
Ул җанның соң кемгә кирәге?
...Төн салкыны...
                    Тәннәр кайнарлыгы,
Һәм берәүнең әрнер йөрәге.

***

Син кил генә,
      килеп ым бир генә,
Мин чигенмәм бүтән, өркемәм.
Быелгының бу кара көннәре
Яктырырга тиеш шул көннән.

Син кил генә,
      яңадан кил генә,
Мин карышмам бүтән һичкайчан.
Бу гомернең янмый сызган шәме
Тик бер дөрләп сүнсен, ичмасам!

***

*(Аклану)*

Сез барыбер мине аңламассыз,
Йөдәтмәгез кабат сорап сез...
Гөнаһларым булса — гаепсездер,
Гаепләрем булса — гөнаһсыз.

Ялганнарым булса — алдау түгел,
Үз күңелем, димәк, инанган.
Ялгышканмын икән — язмыштандыр,
Ничек узып яшим мин аннан?

***

Затсыз тәнем йөри ил каршында,
Дансыз атым күккә чөелә.
Горур башым ялгыз калса гына,
Хәсрәтеннән түбән иелә.

Тәңре биргән җанны биккә салдым,
Шуннан бирле «яшел» юлдамын.
Яшьсез күзем күптән дымны тоймый,
Моң ауламый —
өнсез колагым.

***

Әллә кайда, ерактагы
Яшьлек таңы читендә
Синнән бүләк алдым тагын
Көндәлекләр битендә.

Сине югалткан ул язлар
Табышлырак яз булган:
Иске өметләр югалган,
Яңа җырлар язылган.

***

Кагылынмаган яшьлегем
Синең учта иде.
Җомга гыйбадәте кебек
Керсез, чиста иде.

Син аны читкә тибәрдең,
Кирәк санамадың.
Кабул итмәгән догасы
Мин газиз Алланың.

***

Күрсәм дә күзләрендәге
Карашлар үзгәргәнне,
Юк! Ташкыннарга күпердән
Ташламыйм үз гәүдәмне.

Аңласам да бөтенләйгә
Сүнү-сүрелүеңне,
Ташлауларың хурлыгыннан
Чикләмим гомеремне.

...Киткәннәрнең кайтканы бар,
Анысы вакыт эше.
Өметсез түгел тәненнән
Җаны чыкмаган кеше.

***

Явыз яз харап иткәндәй
Көйдереп бөреләрне,
Йөрәкнең якты ялкынын
Сүзнең бар сүндергәне.

Бер саксыз әйтелгән сүзнең
Шуңа китергәне бар:
Туарга торган бәхетне
Тумый үтергәне бар.

***

*...га*

Хатларыңны саклыйм,
моңа кадәр
Санамаган идем саннарын.
Байтак алар...
һәм һәр юлы саен
Синең йөрәк яши аларның.

Синең хисләр,
син яраткан төсләр,
Күктән төшкән түгел, җирнеке.
Син биектә үзең,
бу романның
Әче даны гына минеке.

***

Минем сөю ак болыттай
Югары кебек иде.
Бармак белән кагылсаң да,
Югалыр кебек иде.

Син килүдән, син тиюдән,
Син сөюдән бу җаным
Үзгәрде дә, үзгәртте дә
Бөтен төсен дөньяның.

...Бу җан гөнаһлы сөюдән
Тыелып каламыни?
Җирдәгеләр җирдәгедән
Котыла аламыни?

***

Кемдер карый кемнәр күзенәдер,
Кемдер карый күккә, биеккә.
Мин күккә дә карашымны атмыйм,
Йөрмим башым җиргә иеп тә.

Юк, эзләмим синең күзләрне дә,
Аларда да түгел мин көткән.
Битарафлык, бушлык тирә-юньдә,
Хәзер мин дә шуңа күнеккән...

***

Без, хатын-кыз: «Ир-ат — терәк», — диеп,
Иблисләрне күпме яр иттек!
Затыбызга ук ят манкортларны
Ил тутырып җирдә бар иттек.
Яшьлегемдә нәсел дәвамымны
Шул чакларда, Тәңрем, яраттың...
...Бер пәйгамбәр тудырасым килә!
Яшьлегемне кайтар, йа Раббем!

***

Сылу таллар. Нишли алар, —
Күзге итеп Зәй суларын?
Әле үреп, әле сүтеп
Бөдрә-бөдрә толымнарын.
Сылу таллар. Нишли алар,
Су—көзгедән ни сорыйлар?
Суга багып, тарак салып,
Яз башында ни юрыйлар?
Ярда үскән сылу таллар,
Язмыш белән уйнамагыз,
Бәхет көткән гашыйкларга
Аерылулар юрамагыз.
Язмыш белән уйнамагыз,
Сылу таллар, сылу таллар,
Язмыш белән уйнамагыз,
Сылу таллар...

***

Бәгырем, иркәм, диген,
Тик сине көтәм, диген,
Гомерем буена сине
Уемда йөртәм, диген.

Тик сине сөям, диген,
Син генә диям, диген,
Киләчәк бәхеткәем дә
Тик синең белән, диген.

Сөйләр сүзең дә дөреслектән
Ерак булса ничаклы,
Шулкадәре тиз ышаныр —
Хатын-кызлар беркатлы.

***

«Аккошым», — диделәр,
«Язмышым», — диделәр,
Иһи, саный китсәң алар әйткәнне!

«Әй генә», — диделәр,
«Мәңгегә!» — диделәр,
Бар да чакырдылар —
беркем ияртмәде.

***

Таңнарның чыклысын,
Кичләрнең айлысын
Җырлап та, елап та
Кайтара алмыйсың.

Елап та, җырлап та
Чакырып карадым
Яшьлекнең табигый
Кичләрен, таңнарын.

Тик алар кайтмаслык
Еракта калганнар —
Таңнарны, кичләрне
Үзгәртте заманнар.

Айдагы Зөһрә кыз
Сурәте югалды.
Таңда чык агулы,
Агулы кыравы.

Инде үз чигәмдә
Сыкылар, кыраулар,
Җыр түгел, телдә дә —
Тәүбәләр, догалар...

Хатадан гыйбарәт
Яшәвең каргышын,
Күпме кыл гыйбадәт, —
Юк, юа алмыйсың.

***

Язлардан алда җанны җилкеткән
Чит иде микән? Үз иде микән?
Язлардан алда җанны җилкеткән,
Таңда сандугач җырын ишеткән

Чит иде микән? Тиң иде микән?
Таңда сандугач җырын ишеткән,
Яшьлек таңымда ярым дип йөрткән
Чит иде микән? Син идең микән?

Яшьлек таңымда ярым дип йөрткән.
...Күңелем тәрәзәсен яңадан чирткән
Син түгел икән, син түгел икән,
Син түгел икән...

***

*(Нәүрүз көндәлегеннән)*

Урамнарда кояш,
кояшта да бу баш
Күтәрелми нигә, яктырмый?
Җир-дөньяның шундый гаделсезлегенә
Хак-табигать үзе аптырый.

Язмышларың тоташ
рәнҗетүле булгач,
Нечкә күңел сына гел юктан,
Урамнарда кояш,
кояшта да бу баш
Ник арынмый кара болыттан?
Китмә, китмә, кояш!
Һаман болай булмас.

Бу башларның ниләр күрәсен
Тәңре белә үзе,
илдә Нәүрүз көне —
Өмет шәме сүнә күрмәсен,
Өмет шәме сүнә күрмәсен!

***

Ничә ел аша бу күңел
Борыла туган якка.
Иң акылсыз, тыелгысыз
Җырларым калган чакка.

Күтәреп килсәң әгәр дә,
Ярым, шуларның берен,
Иң акыллы бүгенгесен
Алмашка бирер идем!..

***

Күптән инде хатлар килми миңа
Син яраткан зәңгәр букчада.
Килми хатлар Яңа ел туса да,
Язлар алмашынып торса да,
Килми хатлар синнән.

Элек-элек, байтак еллар элек
Синең кулың белән язылган
Шигырьләрне, догалыклар кебек,
Калдырмыйча йөртәм янымнан.
Әйтерсең лә алар тапталудан
Мине саклый торган талисман.

***

Әллә нинди югалтулар белән
Чеметтерер кебек бу язлар.
Китеп барсам әгәр,
жан дәвалар
Шигырьләрне минем кем язар?

Шагыйрәләр бездә юк түгел лә,
Алар мине ничек аңларлар?..
Болар түгел,
минекеләр түгел —
Бүтән булыр алар язганнар.

***

*Казанга*

Синдә үтте минем нинди еллар!
Ул елларның әче таңнары
Күпме мөмкинлекне урладылар,
Күпме мөмкин булмаганнарны.

Синдә төште чәчкә бу сыкылар.
Кем хәтерли сәбәп-җирлеген?
Синдә алган җәбер газабыннан
Арыналмый, һаман чирлимен.

Юк! Мин монда сине сагынып килмим,
Мин үч алам синнән үземчә.
Иягемне күккә чөеп йөрим
Баш та какмый, сәлам бирмичә.

***

Син киткән көздән соң
Син үткән эзләрне
Бу бакча моңаеп
Яңадан күзләде.

Бу бакча моңаеп
Ялгызы күзләде.
Син киткәч, ярың да
Бу ярга килмәде.

Килмәде ярың да
Бу елга ярына.
Бакчада эзләре
Күмелде аның да.

Син киткәч, аның да
Эзләре юк монда.
Ул ерак, ул инде
Мәңгелек йортында.

...Тик бакча, тик елга
Хәтерли үткәнне:
Сөюдә хыянәт
Гомерне кискәнне.

## Афәт

Җанда шундый тынлык, оеганлык,
Саңгыраулык арган җанымда.
Ишегемне кайтып син каксаң да,
Ишетмәмдер төсле аны да.

***

Уңган, булган хатын белән
Рәхәт чигеп яши бир.
Балагыз юк. Анысы инде
Ташланган кыз яшедер.

Анысы инде күптән кылган
Гөнаһларның әҗере:
Ташланган яр карынында
Туар бала кабере.

Алар тыныч.
Бу дөньядан
Югалганнар дәшмидер.
...Уңган, булган хатын белән
Рәхәтләнеп яши бир...

***

Һәр кешегә аерым бер бүлмә,
Тарлык бирмә, Тәңрем, күңелемә.
«Монда кермә!»
«Боларга тимә!» — дип,
Ишек саен, күңелем, бик элмә,
Һәр кешегә аерым бер бүлмә...

Киң вә иркен аерым бүлмәндә
Тараймасын күңелең, и бәндә!
Бикле—биксез малың иярмәс
Тар гүрләргә тәнең кергәндә.
Керәселәр анда бар, диләр,
Менә анда ятак тар, диләр...

***

Үткәннәре уртак булды,
алдагысын
Шулай сорыйм Тәңредән
чын күңелем белән:
Син төшкән җир — минем
төшкән урыным булсын,
Күтәрелсәң, мине дә ал
үзең белән.
Синең янда иңем дә нык,
кулым да нык,
Канатында талпынадыр бәхет кошым.
Син булмасаң — өем дә юк,
улым да юк —
Шул өчлектән башка нинди бәхет булсын?!
Мин гел сөйдем,
Бер дә сөйдем, мең дә сөйдем,
Берендә дә, меңендә дә сине сөйдем,
Әгәр тагын егерме кат кайтса гомерем,
Барысында да һаман сине эзләр идем.

***

Сабый чагым. Җиде яшьлек чагым,
Иреннәрдә әрем әчесе.
Өзелеп килә иде ашыйсы һәм
Ачлы-туклы килеш яшисе.

Үсмер чагым. Ундүрт яшьлек чагым.
Хыялларда илнең ямьлесе.
Өстә — киемнәрнең ямаулысы, —
Шундый килә иде киенәсе,
Җитәр-җитмәс тормыш иткәндә дә,
Шундый килә иде яшисе...

Яшьлек чагым. Студентлык чоры.
Киләчәкнең алда яктысы.
Шигырьләрнең шундый өметлесе,
Гел биеккә дәшкән яхшысы.
Шундый килә иде яшисе.

Өлгерепләр тулып җиткән чагым!
Көн-төн эштә, эштә таң-киче.
Җигелеп-чабып ардым, хәлдән тайдым.
Барыбер килә иде яшисе,
Килә иде шундый яшисе...

Инде менә олыгаеп калдым,
Бер артыма, бер алдыма карыйм,
Үтелгәннең күпме хатасы бар.
...Күреп бетермәгән төшләремне
Ләхетемдә күреп ятасым бар.
Каберлектә ташның яшьлесе.
Әле һаман килә яшисе!

***

Киләчәк көн турында да,
Узганнар турында да,
Күбәләк канатындагы
Тузаннар турында да,
Көз кергәч кенә яшәргән
Агачлар хакында да
Җырладык, тиңләп дөньяны
Көлгә дә, алтынга да.
Көтмәгән чагыштыруга
Беркатлы ышанганлык
Кемнедер ышандыргандыр,
Үзебез ышанмадык.

Ирекле сәнгать, мәхәббәт,
Ирекле дигән бәндә
Җырламый микән сәхнәдә
Тик акча түләгәнгә?

***

Мин хыялда гына җыйган байлык,
Мин төшләрдә күргән хәзинә
Булсын, диеп, аяк асларында
Үзем риза булып эзенә.

Көннәремдә таңнан эшкә чаптым,
Кичләрендә яздым, укыдым...
Кичен өлгермәгән кадәренә
Төннәрендә торып утырдым.

Син тәмлерәк миннән ашасын дип,
Матуррак миннән кисен дип,
Тапкан-табынганым, җыйган малым,
Куйган көчем улым өчен дип.

Нәтиҗәдә — һәрбер ата-ана
Татый торган җимеш аллана,
Ана күңеле һаман балада да
Бала күңеле читтә, далада.

Ярый да бит синең күңелеңнән
Безне этеп-төртеп чыгарган
Ул кыз бала иманлы зат булып,
Яшь түкмәсә кабат бу анаң.

Ярый да бит үзе яраткандай
Сөйдерә алса сезне, ирләрне,
Һәм сөюен бәяләтә алса...
Минем кулдан анысы килмәде.

***

Үлемнән дә курыкмаска кирәк,
Ул барыбер килә кайчан да.
Ул барыбер сине таба эзләп
Курыксаң да, курыкмасаң да.
Ә гөнаһтан курка белү кирәк,
Кача белү кирәк гөнаһтан.
Кылгач тәүбә итү белән түгел,
Кача белү кирәк кылмастан.

***

Соң минутта кемгә караш салыр
Соңгы-соңгы яшьле зарлы күз?
Кәгазьләрдә кем кулына калыр
Соңгы шигырь, соңгы парлы сүз?

Әйтеп булмый, кемнәр белсен аны?
Тик йөрәктә йөртәм инде мин
Шул теләкне: сездән калып түгел,
Сездән алда китсәм иде мин.

Бу — үземне яратудан түгел,
Бу теләгем сезне сөюдән,
Һәм ул сөю сездә ул кадәр үк
Түгеллеген тоеп белүдән.

***

Сагышларга башны салмыйк әле
Җәй ахыры җиткән чагында.
Син боекма, охшап төнбоекка,
Син саргайма, охшап каенга.

Изаланма, охшап аккошларга,
Кәккүкләргә охшап, моңайма.
Шиңми, сулмый керик ак кышларга,
Шөкерана кылып дөньяга.

Җомгаларда җыйган җир җиләген
Кышлык өчен куйдым киптереп.
Кышкы салкыннарда чәй эчәрбез
Питрауларны искә төшереп.

***

И Шигырем!
Нигә табына идең —
Тугрылыклы булып кал шуңа.
Хәзер бар да көнне сүгә диеп,
Ач хәерче кебек шыңшыма.

Бисмилладан качкан шайтан кебек,
Йөз чөермә Илдән, тайчынма.
Ни-нәрсәгә, Шигырем, табына идең —
Тугрылыклы булып кал шуңа.

***

Үтә быелгы кышлар да...
Фасылга нәрсә аңа?
Ул быел үтсә, яренгә
Яңадан кабатлана.

Тик менә гомер дигәнең
Яңадан кайтмас инде...
Кайтса да, яшәү мәйданын
Бу җирдә тапмас инде...

И Алла!
Без бит сиңа да
Борылдык әле генә.
Сондыр шул! Кылган тәүбәләр
Ирешмәс Тәңерегә.

Без түгел юкса гаепле
Тормыш салуларында
Башлар яткан чаналарның
Болай чалулавына.

Үтә быелгы кышлар да,
Вакытка нәрсә аңа?
Фәһемсез үткән гомердән
Әрнүдән акыл яна.

***

*Якташыма*

Күзгә төшкән кояш нурлары да
Җанга төшкән дөнья яме дә,
Күңелләрдә туган җырларым да
Туган яктан килә, Сәгыйдә.

Кырда үскән иген исләре дә,
Мичтә пешкән ипи тәме дә,
Туган җирне сөю хисләре дә
Шул төбәктән килә, Сәгыйдә.

Иҗатымның башы шул Сарманда,
Дәвамы да шунда.
Әле дә,
Шигърияткә җаным сусаганда,
Мин Сарманга кайтам, Сәгыйдә.

***

Бу чияләр шау чәчәктә иде
Әле кичә генә.
Чәчәкләрен коеп хәсрәт җиле
Бүген исә менә.
Вакытыннан алда җиргә төште
Чәчәкләрнең таҗы.
Шул суыклар суккан бөре төсле
Ташланган яр җаны.
«Мин ансыз да яши алам», — диеп,
Хәл иткәнсең икән —
Шулай булсын...
Әмма бер көн килеп
Үкенмәссең микән?..

***

Карт башына яткан кар аклыгы
Кырау гына түгел икәнен
Белгән кешеләрнең куактагы
Сыкыларга исе китмәвен

Белми идем мин дә.
Инде менә
Кыл уртасы үткәч гомернең,
Акыл аңлый гомер фасылларын
Кабатлаулар мөмкин түгелен.

Акыл аңлый,
йөрәк аңлый алмый,
Тыпырчына, язда калам, дип,
Аңлый алмый!
Үзен һаман алдый —
Яздагыча сөя алам, дип.

***

Сарман юлларында сары чәчәк
Төшләремә керә сибелеп,
Кайта алмый йөргәнгәдер инде,
Сагышлардан үзәк өзелеп.

Сары чәчәк сагыш төседер лә,
Сагышлану эзсез үтмидер,
Күңелләрем белән шул якларда,
Әле генә юллар төшмидер.

Кайта алмый йөргәнгәдер инде,
Сагынулардан үзәк өзелеп,
Сарман буйларының сары гөле
Төшләремә керә сибелеп.

## Әлмәт. Рәсемнәр күргәзмә залында

Җәйге җәйләүләрдәй иркен идән,
Яшел чирәм кебек яшел келәм,
Диварларга
рәссамнары элгән
Рәсемнәргә бөтен тарих кергән.

Элпә томан зәңгәр елга өсте,
Утлы ялкын сары көнбагышы,
Натюрмортлар,
Тукай гомеренең
Батмас өчен килгән көн баешы.

Иҗатында Тукай булмасаң да,
Шуны бирер рәссам булсаң икән.
Күргәзмәнең һәрбер күзәнәге
Тукай рухы булып җанга үтә.

## Дуамал җыр

Гөнаһлымын,
гөнаһымның
Җәзасыннан баш тартмыйм.
Әгәр сөю гөнаһ булса —
гөнаһлымын, яраттым.
Әгәр сөю гөнаһ булса —
гөнаһларым әз түгел.
Гөнаһ дими, тәүбә белми,
Игә килми бу күңел.

Сөяр фани дөньяда да,
Ахири дөньяда да,
Сөеп туктамас анадан
Яңадан туганда да.

Соң шул сөю гөнаһ булса,
Гөнаһлымын — баш тартмыйм.
Гөнаһы да, җәзасы да
Үземнеке — яраттым.
Яраттым шул,
яраттым.
Гөнаһлымын — яраттым.

## Бер генә

Күк йөзендә кояш бер генә,
Баш өстемдә күгем бер генә,
Җирдә яшәр гомерем бер генә,
Гомер итәр ирем бер генә.

Кояш уртак бөтен кешегә,
Күкләр уртак җирем өстендә.

Гомерем уртак Халкым, Илемә,
Уртаклашмас нәрсәм — син генә.

Халкым әйткән сүзләр бик хаклы:
«Тәңре хакы бездә — ир хакы».
Мин хакыңны хаклап яшимен,
Саклап,
яклап,
аклап яшимен.

***

Улым утлы борчулы бу араларда.
Шундый мәле килде язның балама да —
Тамагына ашы үтми,
йокысы качты...
Газиземне нинди кайгы-хәсрәт басты?

Тулган айдай тулы йөзе сулып калды,
Күзләренә нидән бу моң, сагыш сарды?
Кояшка тиң елмаюы ник югалды,
Газиземне кемнәр мондый утка салды?

Һай, баламның саф күңелен кем җилкетте?
Җилкетте дә җилбәзәк ник ташлап китте?
Җан-егетнең горурлыгын ник кимсетте?
Кайсыгыз ул?! Ни атлы кыз шулай итте?

Кайсыгыз ул сары якты ал йөзенә,
Башын чөеп чыкмас итте урамнарга?
Сыкранусыз карый алмыйм газиземә,
Ана җаны кушылып көйри ул янганга.

Балакаем! Ни дәва соң бу ярага?
Нинди дога? Нинди сихер, тылсым көче?
Бәлки, үтәр, бәлки, вакыт дәвалар да.
Тоеп торам: бик авыр шул бүгенгесе.

Ник улымның язын шулай каралттыгыз?
Ник Алласыз рәвештә газаплыйсыз?
Төн йокысын качырдыгыз, ашатмыйсыз,
Кайсыгыз ул — таш бәгырьле? Ни атлы кыз?

***

Ул колхозның бригадиры иде,
Ул ярата иде кырларны.
Арыш баш кысканда, сугыш килде,
Урдырып та хәтта булмады.

Бригаданың дүрт егете белән
Беренчеләр булып киттеләр.
Шул китүдән бүтән кайтмадылар.
Кайтмаганнар илдә күпмеләр...

Каберләре бөтен Европада,
Исемнәре ташта, мәрмәрдә.
Карчыклары басу капкасында —
Арышлар баш кыскан мәлләрдә.

Эше-эзе шушы җирдә һаман,
Үзе яши кебек бүген дә
Болыннарда үскән ромашкада,
Басуларда үскән игендә.

***

Атнага бер генә
Көндәлек ачыла,
Язасы иде дә —
Кул җитми ансына.

Унга да йөгерәм,
Сулга да йөгерәм,
Кайсына өлгерим —
Әле дә өлгерәм.

«Җомга»сы өстенә
Әдәби түгәрәк.
Районда, калада
Гел йөрим тәгәрәп.

«Кайда соң яшьләр?» — дип
Сорамыйм. Беләсез,
Яшьләр бар,
тик алар
Эшләми түләүсез.

Юк хәзер безләрдәй
Акылсыз кешеләр.
Акчасыз йөрмиләр —
Һәм дөрес эшлиләр.

Без генә ул менә
Мәгънәсез эт җиккән
Сәхнәдә йөрибез
Дермантин итектән.

Үзебез һаман да
Сагынабыз үткәнне...
Дуңгызны, йолдызны
Тигезләп киткәнне.

***

Күзәткәндә тау бөркете очышын,
Тизләтәсең канатыңның үз көчен,
Көчәйтәсең күзләреңнең карашын —
Җирне, күкне бергә күрә аласың.
Күзәткәндә биек очкан кошларны,
Җан чакыра ерак киткән дусларны.
Тыңлагыз, әй, үз күргәннәр кушканны:
Җир кичерми илен ташлап очканны!

## Хәтер тәрәзәләре

Колшәрип басуларына
Зәңгәрләнеп таң инде.
Таңнарны шул басуларда
Каршылаган бар иде.
Шул якка карый тутырып
Палата тәрәзәсе.
Таңнарда, качыпмы чыгып,
Әллә бер әйләнәсе?..
Бар әле, күңел, эзлә әле,
Табылмас микән шунда
Яшьлекнең тирән эзләре —
Сай Дөмәй елгасында?
Җәяү дә йөри идең син,
Җайдак та йөри идең:
Яшь идең, ару-талуны,
Авыруны белми идең.
Яз булса, чәчүчеләр дә,
Җәй булса, уракчылар
Көтәләр иде үзеңне:
«Кайчан, — дип, — килеп чыгар?»
Телләрең җырны-шигырьне

Гел көйләп торгангамы,
«Тургай» дип йөртте үзеңне
Әшерәп Галимҗаны.
...Бүген дә әле урының
Колшәриптәдер кебек.
Дөмәйдә күчмә вагоннар
Гәҗит көтәдер кебек.
Ярышлар нәтиҗәсен дә
Куясы бардыр элеп.
Кил әле, Галимҗан абый,
Тимеркүгеңне җигеп.
Мин үзем йөргән алаша
Үлгән, диделәр, күптән,
Картаеп үлгәндер инде,
Әллә сагынып микән?
Сагыныр... аңа атлансам,
Күпме кыр урый иде.
Аңласа-аңламаса да,
Җырымны тыңлый иде.
Бер җырлый белми идем мин,
Гел җырлап йөри идем.
Үзем уйлаган җырларның
Үзем чыгарган көен.
Син шуңа мине «Тургай» дип
Атаган идең, көлеп...
Кил әле, Галимҗан абый,
Тимеркүгеңне җигеп, —
Кырчылар килеп җиткәнче,
Гәҗитне куйыйк элеп.
Кем нинди урын алган да
Кем нигә артта калган? —
Саннарын гына бир миңа —
Барын да җырга салам.
Кайсы хак, кайсы нахагын
Укырлар, тикшерерләр.
Ә Назил белән Разил

Барыбер кичерерләр.
Ә Назил белән Разил
Ярышның уртасында.
Аларның һаман йә берсе,
Йә берсе алдан чыга.
Бу ике егет, ике дус
Көндәшме эштә генә? —
Кем белсен, аның серләре
Калды яшьлектә генә.
Таңнарда шул кырга чыгып
Килә бер әйләнәсе.
Шул якка карый тутырып
Хәтерем тәрәзәсе.

***

Бик биектә тургай,
        җирдән ерак күктә —
Башың чөеп карамасаң, күренмидер.
Җир турында үзе җырлап гомер итә,
Ул, мөгаен, шуннан башка җыр белмидер.

Син еракта,
        гел чит якта йөргән чакта
Йөрәк янсын, күздән сагыну яше тамсын.
Җир йөзендә тургайсыз яз булмагандай,
Җыр илендә сөюсез кем яши алсын?!

## Оныта алмассың...

Риза булса җаның бүгенгедән,
Канәгатьлек тулса күңеленә,
Китәм, димәс телең торган җирдән,
Кайтам, димәс туган иленә.

Кайнамаса төптә үткәннәрең,
Өндәмәсә өстә иртәгең,
Син кайда да янмый, көйми генә
Күзәтерсең гомер үткәнен.

Тамырыңны, әмма дәвамыңны
Уйларыңда йөртсәң, фикердә —
Оныта алмассың туган туфрагыңны,
Таба алмассың бәхет чит җирдә.

## Өйрәтегез!

Туган якта җәйләүләрне,
Елга, таулар, далаларны
Яратырга өйрәтегез
Шунда үскән балаларны.

Өйрәтегез яратырга
Өйләрен дә, зиратын да...
Ә калганын
тормыш үзе
Өйрәтер үз чиратында.

Яңадан килде бу язлар,
Җемелди көлдәвекләр.
Тирбәлә күктә тургайлар,
Йөгерә гөрләвекләр.
Йөгерә-ага кар суы,
Челтерәп ага көлеп.
Ачыла уҗым басуы,
Ямь-яшел хәтфә кебек.
Кар суы, туктат юлыңны,
Тукта да җиргә сыен.
Җиргә бир шифа—дымыңны,
Шул булыр безгә сыен.
Җәйлектә сабан ашлыгы
Сусаудан кибенмәсен.
Төннәрен көнгә ялгаучы
Игенче көенмәсен.
Кал безнең җирдә, кар суы,
Җир куены иркен безнең.
Ямь-яшел уҗым басуы
Сап-сары булсын көзен.
Шауласын алтын башаклар,
Шауласын кырлар тулып.
Безнең эш кайтсын мул уңыш
Һәм матур җырлар булып.

***

Бүтәндер ул...
                    җырлап,
                              уйнап-көлеп,
Биеп юатучы бүтәндер.
Юатмыйм да,
Тынычландырмыйм да,
Борчый гына алам мин хәзер.

Бәлки, җанны үзең үртәгәнгә
Хисләр шулай туңып беткәндер —
Ә кайчандыр барын күтәргәне,
Җиңел генә көлеп үткәргәне
Мин түгелдер,
                    юктыр,
                              бүтәндер...

***

Зәңгәр күкләр, ак болытлар...
Болытлар ак, күк зәңгәр...
Ах, ни булыр, ак болытлар
Кара яңгыр түксәләр?

Ах, ни булыр, ак болыттан,
Аяз күктән боз яуса?
Ах, ни булыр, бер дә юктан
Илдә давыл кузгалса?

Ах, ни булыр, бер дә юктан
Җимерелсә бу нигез?
Син дә, мин дә чынбарлыкка
Ни дип җавап бирербез?

## Син генә юк чия бакчасында...

Җан йөрәккә моңлы өмет биреп,
Язлар килде тагын Әлмәткә.
Иртәләрне назлы нурга төреп,
Чияләрне күмеп чәчәккә.

Чәчәк ата чия өй каршында,
Парын табып кошлар кавыша.
Син генә юк чия бакчасында,
Язлар инде җәйгә авыша.

Чия исе аңкый һаваларда,
Моң саркыла йөрәк үтәли,
Бу чияләр инде бу язда да
Синсез чәчәк кояр микәнни?

## Инде берук чайпалмасын

Мин бит сиңа гашыйк булам
Тора-тора һаман ныграк.
Тәүге тапкыр сине күреп
Гашыйк булган көнем ерак.

Гашыйк булам улыбызны
Эшкә озатып калган чакта.
Гашыйк булам оныгымны
Кулларыма алган чакта.

И Ходаем! Бу дөньяда
Алар булу нинди бәхет!
Моны җырга булмый салып,
Моны сүздә булмый әйтеп.

Инде берүк чайпалмасын
Тормышымның чынаягы.
Син генә бит, бер генә бит
Бу бәхетнең чыганагы.

Тәүге тапкыр сине күреп
Гашыйк булган көнем ерак.
Ә мин сиңа тора-тора
Гашыйк булам һаман ныграк.

## Әрнүле җыр

И, бар иде нинди чаклар!
Әйтерсең лә чаптар атлар,
Ыргый идек үрдән үрләргә.
Куаныша иде картлар,
Сокландылар хәтта ятлар,
Мәйданнарда безне күргәндә.

Һай, ул көннәр! Яшен, җилләр.
Ут уйнатыр давыл, силләр
Үткән, киткән, искән кай ара?
Инде бүген үзебез картлар,
Мәйданнарда башка атлар,
Тик белмиләр кая чабарга...

Ыргып менәр үрләре юк,
Аяк терәр җирләре юк.
Аларны кем, кайчан юк иткән?
Күңел тулы әрнү җыры,
Өзелүдә буын юлы
Безнең гаеп-гөнаһ юк микән?..

Иң элек сәламәтлеге:
Бар ягы да төгәлме?
Мәктәп куйган таләпләргә
Тәңгәл туры киләме?

Ә аннан соң тирә-юне,
Нинди шартта торуы,
Өченчесе — нәсел җебе,
Кай тамырдан булуы.

Бу бик мөһим.
Тормыш инде
Раслап килгән, тикшергән:
Чүпрәктән чаң коелмый,
Аккош тумый күседән.

***

Ә тормыш бик авыр,
Дөньясы болгавыр.
Борылыш чорында
Гел шулай буладыр.

Тикмәгә японнар,
Ачуы килгәнне
Каһәрләп, шул чорда
Яшәсен дигәнме?

Соң, безнең буынны
Кем, кайчан, кай мәлдә
Әрләгән, каргаган,
Тарсын дип бу хәлгә?

Каргалган язмышта
Ялгыш та буладыр...
Кыйбласыз халыкка
Юл табу бик авыр.

Кыйбласыз, имансыз,
Даһисыз бу заман.
Булганы югалган,
Булыры тумаган.

***

Абынып егылабыз да...
Торабыз, йөгерәбез.
Кайсына өлгермәсәк тә,
Кайсына өлгерәбез.
Кабынып дөнья куабыз,
Дөньясы безне куа.
Кайвакыт бу куышудан
Туктасы килеп тора.
Фәйзулла әйткән шикелле,
Башларны салга салып,
Китәсе килә олагып,
Китәсе килә агып.

***

Ышансаң-ышанмасаң да...
Ышансаң-ышанмасаң да,
Бер юаныч күңелгә:
Йолдызнамә — фал китабы,
Ачыйк әле бүген дә.
Ел башында, и, барсын да

Йолдызнамә юрасын,
Ни буласы булган инде —
Юрасын ни буласын.
Ни буласы булган инде,
Баштан узган төрлесе:
Без хаклык дип инанганның
Хата булган күбесе.
Дөрес, бәндә хаталардан
Хали түгел түгелен,
Гел хатадан торган көне
Бик авыр шул илемнең.
Искеләрен төзәтик дип,
Яңаларын ишәйтеп.
Ипле генә яшәр көнне
Куйдык әллә нишләтеп.
Ни буласы булган инде...
Уйлыйк ниләр буласын,
Берүк инде Яңа елда
Яңа афәт тумасын.

***

Аклы яулык, ак бөрчеккәй яулык —
Әнкәемнең соңгы бүләге.
...Тик ул аны, сандыгыннан алып,
Үз куллары белән бирмәде.
Өлгермәде үзе өләшергә...
Хәстәрләргә хәтта җитешми,
(Ни көткәнне кайчан кемнәр белә?..)
Китеп барды кинәт бер кичне.
«Йоклыйм» гына диеп яткан җирдән
Иртәгесен торып йөрмәде.
...Бөрчек-бөрчек күз яшьләрем юа
Яулыгының бөрчек бизәген.

***

Юлларның чаты да,
Очы да югалган,
Акыллар буталган,
Саташкан бер заман.
Артка да кайталмый,
Алга да баралмый,
Элгәрге белем дә
Бернигә ярамый.
Юнәлеш күренми
Үтәргә бу көннән,
Үткәнгә кайтырга
Күперләр сүтелгән.
Таяныр нокта юк,
Табыныр кыйбла юк,
Артыннан иярерлек
Пәйгамбәр — ул да юк.

***

Башы-соңы бергә төйнәленгән
Бу сорауны ничек чишәргә?
Чик-чамасыз бизмән ялгыш булгән
Бу тормышта миңа нишләргә?

Усал язмыш-бизмән сине миннән
Тартып алып, салгач башкага,
Алиһәләреңнең аллаларын
Аздырсам да гаеп ташлама!

***

Кем кемгә бүген илтәдер
Гөлнең хуш исләләрен,
Мин шигырьләр бүләк итәм
Сезгә, Игенчеләрем.

Минем өчен ике исем
Әнидән соң изгесе!
Беренчесе — Туган җирем,
Икенчесе — Игенче.

***

Тулыр-тулмас сыңар гомеремдә
Мәктәпләрнең үттем ничәсен?
Ялгышырсың әгәр алар бар да
Якты җәннәт булган дисәң син,
Ялгышырсың...
Шөкер, бу яшәүнең
Йотылмадык ләме-сазына.
Рәхмәт якты, татлы газапларын
Җырга сала белгән җаныма.

***

Син кузгатма инде тынган җанны,
Алгысытма арган күңелне.
...Эх, нигә дип әле оныта алмыйм?
Йокылары качты күземнең...
Эх, нигә дип әле оныта алмыйм?
Тирәнлектә өмет туса да,
Арада бит тирән упкын яры,
Арада бит утлы бусага.
Син кузгатма инде бу җанымны,
Син кузгатма инде, кузгатма...

## Соң булса да...

«Соң булса да уң булсын», —
дип әйтә халык,
Соң булса да башка шундый фикер төшкән.
Явызлыкның чыганагы — имансызлык,
Имансызлык чыганагы нәрсә икән?
Ул чыганак, бәлки, безнең чиктән чиккә
Ташланудыр кылганнарда, планнарда.
Инсафлылык, әдәплелек төшенчәсен
Алга куймый ыргытудыр узганнарга.
Бәлки, безнең җиргә килгән сабыйларга
Көн сабагын дөрес бирә белмәүдәдер?
Туган җирне, туган илне яратуга
Туган телне яратудан килмәүдәдер.

## Игенче җаны

Ни афәт — явымнар юкта
Кичергән, үзе белгән...
Ымсынып карый офыкка
Ялвару күзе белән.

Киптереп яшен күзенең,
Йөзенә тамчы төшә.
Уҗымнар яшел-күгелҗем —
Өметле җилләр исә.

### ***

Яз айлары җиргә тагын килер,
Гөрләвекләр тагын йөгерер.
Йөгергәндәй язгы гөрләвекләр,
Ник ашыга икән бу гомер?

Элеккечә әле мартның башы,
Хәзергечә — инде уртасы.
Бу язларны гомер уртасында
Үткәрмичә ничек тотасы?..

Март уртасы алдар чак икән лә,
Җил җилдереп алдан чап икән.
«Язлар алда» диеп алдансаң да,
Гомерең көзе килү хак икән.

Язлар җыры тирә-ягым тулы.
Гөрләвекләр агар тагын да.
Ил алдында йөзем ак булырмы,
Көзге уңыш җыйган чагымда?

### *Исемсез җыр*

Оныттыңмы серле Әлмәт көзен,
Төштәгедәй өнен шул көзнең?
Мин ул көзнең тылсымчысы идем,
Хуҗа идем сиңа берүзем.

Акылыннан язып Ләйләсенә
Гыйшык тоткан Мәҗнүн шикелле,
Синең күзләр бөтен Әлмәтендә
Күрми иде бүтән һичкемне.

Тылсым көчем кайчан юкка чыкты?
Ни суытты синең күңелне?
Мәҗнүнлектән сине ни айнытты?
Синсез калдым нигә бу көзне?

Өннәр инде төшкә охшамый да,
Ышандырды язмыш шунсына!
Бу тормышта бар да юкка чыга,
Юкка чыга сихри тылсым да.

Ни соралса, шуны түләп менә
Кайтарыплар алмас идемме
Үзем генә бөтен Әлмәтемдә
Бер сихерче булган көземне.

## *Күңел күкләремдә болыт ята*

*(Салкын җыр)*

Салкын кышлар керде,
җир өсләрен
Каплап-күмеп ап-ак кар яуды.
Ап-ак кардай ап-ак күкрәккәем
Хыянәтеңнән синең карайды.

Ап-ак күкрәгемнең эче көйде,
Йөрәккәем калды күмергә.
Керсез җаным хыянәтчел ирне
Кичерә алмас кебек гомергә.

Күңел күкләремдә болыт ята,
Хыялларга офык тарайды.
Ап-ак кышлар юкса тирә-якта,
Кара җирне күмеп кар яуды.

## Нәүрүз җыры

Яз бәйрәме Нәүрүздә
Очрашты күзләр күзгә.
Карадым да күзләренә —
Ут капты йөрәгемә.

Ала алмыйм күземне,
Әйтә алмыйм сүземне.
Ятлар алып югалмаса
Ярар иде үзеңне!

Кушымта:

Их, белмисез хәлләрем,
Башларым әйләнгәнен,
Башларым әйләнгәнлектән,
Телләрем бәйләнгәнен.
Кемнәр уйлап тапкан икән
Бу Нәүрүз бәйрәмнәрен?!

Күлмәгең яшел иде,
Карашың яшен иде,
Шуннан бирле тынгы белми,
Йокысыз яшим инде.

Бу Нәүрүз үтәр инде,
Язлар да китәр инде,
Җәйләр буе күрешмәсәк —
Бу йөрәк нишләр инде.

Кушымта.

Соң насыйп булгач безгә
Танышулар Нәүрүздә,
Ходай насыйп итмәс микән
Кавышуны да көздә?

Кушымта.

***

И, и генә, и ил генә дидек,
И туган ил дидек бер генә.
Туган илдән матур җирләр эзләп,
Күпме җаннар читкә сибелә!

Дус-туганнар булып гомер кичеп
Яшәгәннәр нигә үзара
Сугышалар бүген?
Синең өчен,
И илкәем, йөзем кызара.

Хәйран дөньяларны вәйран итеп,
Шушы хәлгә илне төшергәч,
Җәрәхәтле килер буын өчен
Җир-табигать безне кичермәс.

## Ком сәгате

Ком сәгате...
һәр бөртеге
Гомерләрнең бер көне.
Бөртекләп тормады язмыш —
Дәррәү тотып селкеде.

Әллә җиргә сыенасы,
Әллә күккә багасы.
Безнең гомер сирпелгән җир —
Җир белән күк арасы...

***

Ярый әле җырым тына белми!
Калган булса әгәр тукталып,
Минем җирне ничек сөюемне
Кайдан белер иде бу халык?

Яшьлегемнең зәңгәр иртәсендә
Теләгәнем бары хыялда
Көнгә ашмый калган булыр иде,
Ярый әле җыр бар дөньяда.

Бу күңелгә нинди мизгел килми...
Өметсезлек тигән көннәрдә
Ярый әле җырым тына белми,
Ирек бирми җанга сүнәргә.

## Май башлары...

Шушы көннәр әни туган көннәр иде,
Аңа йөрү гадәтемә кергән иде.
Еллар үтеп югалдылар ул гадәтләр,
Вакыт җитми, җитми генә көн-сәгатьләр.

Төннәр үтә, кимерелеп китә бара,
Көннәр үтә, таң атмастан көн тарала,
Еллар үтә... Нишләп үтә? Әниеңнең
Каберенә барыр өчен көн таба алма...

Ә-й, дөнья! Ни дип сине куабыз без?
Фанилыгың белә торып куабыз бит!
Үзең безне син үзеңнән куганлыкны
Белә торып, нидер кылмак булабыз бит.

Кылган гамәл игелекле булса икән,
Ул вакытта кылансак та ярар иде.
Сул фәрештә күп теркәми, уңдагысы
Дәфтәренә ни дә булса язар иде.

Юк шул, юк шул... Сулдагысы безнең эшне
Өлгерә алмый дәфтәренә язар өчен.
Ә уңы буш, игелекле гамәл өчен
Вакыт җитми. Өлгермибез алар өчен.

## *И Алла...*

Ел артыннан еллар кыелып тора,
Кайчак дөнья кара коелып тора,
Кайчагында бераз елмая —
Шулай бара яшәү дөньяда.

Кайчак дөнья аннан, ә кайчакта
Үзе бу дөньядан туя да —
Мәҗбүр була дөнья куярга.

Кемдер чиратында куя аны,
Кемдер... чиратын да көтмичә.
Алай дисәң, шул бер тәкъдир инде:
Кем дә китми тәкъдир җитмичә.

И Алла!
Ә китәсе килми шулай да.
Еллар арты еллар кыелып бара,
Нидер кала бездән дөньяда...

***

Без барыбер бер күрешербез әле
Кайчан булса, кайда булса да.
Эзләп йөрмим. Беләм, таба алмам,
Синең юллар киткән еракка.
Илдән китеп бардың.
Шулай язган.
Китәсе мин калдым бу якта.
Синең якта. Ә бит минем анда
Кайдан килеп чыккан булуым
Берәүгә дә мәгълүм түгел иде...
Шунда үткән тормыш юлымның
Серле башы мәңге ачылмыйча
Ияреп йөри гомерем буена.
Мин китәсе идем. Китми калдым.
Синең якта, синең урында.
Синең юллар, әйе, әллә кайда,
Йорт хуҗасыз синең бусага,
Тик барыбер, беләм, күрешербез
Кайчан булса, кайда булса да.

## Яшәештән берүк йөз чөермә!

*Рәзинәгә*

Яшәештән берүк йөз чөермә,
Юнәлешен рухың бер табар!
Дөньяларны тоташ дошман күрмә —
Бу гөнаһлы Илдә без дә бар...

Кыйбла җуйган тормыш тарихының
Кеше гомере — бөртек тузаны.
Котырынган заман агышының
Бер син генәмени корбаны?!

Ник хәбәрең юк соң? Ничек итеп
Хәлләреңне белим?
Кайларда
Йөрисең син?
Әллә җирдән китеп
Күчендеңме ялгыз Айларга?

Дөньяларны ташлап китә күрмә!
Бу гөнаһлы җирдә без дә бар...
Яшәештән, юк, юк, йөз чөермә —
Юнәлешен рухың бер табар!..
Табар!

## Нократ-Елга

Ничә еллар йөрим инде шушы юлда —
Күпме үттем синең аша, Нократ-Елга.
Кайта-кайта бабаларым кочкан чорга,
Синнән килә нindидер моң безнең җырга.
Нократ-Елга! Нократ-Елга тирән уйда.
Ил язмышын уйлый төсле һаман ул да.
Инәлепләр җирдән сузган томан-кулда
Халык гамен күккә юллый Нократ-Елга.
Ярларында уйчан таллар, киртләч ярлар.
Үткәннәрнең хәтерлидер барын алар.
Үткәннәрдән киләчәккә барыр юлга
Дога юлла, күпне күргән Нократ-Елга:
Күпне күргән татарымның бер баласы,
Бу якларның якын миңа үр-даласы.
Хозурлыгын туган җирнең салып җырга,
Халык моңын җыеп йөрим мин бу юлда.
Һәр сәгате көннең җанны кисеп уза
Бу еллардан афәт тулы хәвеф елда.

Үзәк юлда кабер ташы уңда, сулда,
Тарих бүген ни калдырыр, Нократ-Елга?
Ил гаменнән шагыйрь һаман сыкрап тора,
Җирләр, күкләр мәрхәмәсен сорап тора.
Үткәннәрне бүгенгегә ялгап кына
Киләчәкне саклап була, Нократ-Елга.
Нократ-Елга!
Нократ-Елга,
без гел юлда,
Бутала да чуала юл елдан-елга,
Юл язганга юнәлеш бир туры юлга,
Догада бул! Дога юлла, Нократ-Елга.

## Сөю турында янә бер җыр

Ак каеннар җырлый сөю турында,
Зифа таллар җырлый сөю турында,
Көмеш чишмә җырлый сөю турында,
Мин әлегә әйтмим синең турында.

Син шулай да тыңла каен җырларын,
Син шулай да ишет таллар сөйләвен,
Күңелеңә сеңдер чишмә көйләрен —
Аңлашылыр шуннан кемне сөйгәнем,
Мин әлегә үзем берни сөйләмим,
Сөйләмим...

***

Яр буена төшкән борма сукмакта
Кичтән генә үткән парлы эз ята.
Иртә таңда аны, белмим, кем күрер,
Озын телләр күрсә, озак сүз йөрер.

Якты җаннар күрсә, яман сөйләмәс,
Якты таңда ярдан керләр эзләмәс!
Үз яшьлеген истә саклый алганнар
Шикле фикер йөртмәс, гайбәт сөйләмәс.

***

Үз өеңә кайтып үлде улың,
Үз җирендә аны җирләдең.
Бу кайгыдан җаның кара көйде —
Тик үтәлде, ата, теләгең.

...Күпмеләрнең газиз балалары
Ятып калды ерак тауларда.
Юаныч юк алар кайгысыннан —
Икеләтә авыр аларга.

***

Барла, әйдә, фәкыйрь байлыгыңны,
Җыйна, төйнә — күпме язылган!
Һәм барысы өчен гафу сора
Соңгы юлга чыккан җаныңнан.

***

Яшь чагында күңел иркен булган:
Һич кыса юк җанда хисеңә —
Тулаемы белән җыеп торган
Бу дөньяда бөтенесен дә.

Олыгайгач менә гаҗәп икән,
Бөтенесен сынап карыймын:
Кире кагып кына кабул итәм
Бу дөньяның бөтен барлыгын.

***

Җирдә яши адәм балалары,
Фани дөнья көнен кичерә.
Фани дөньяда да Иман кирәк,
Денен саклау кирәк кешегә.

Күңелдәге якты иман нурын
Эш аклаган, хезмәт саклаган.
Сакчы иткән аңа халык моңын
Кадимидән, әүвәл чаклардан.

Моңлы җанга җеннәр ияләшми,
Мәкер булмый моңлы күңелдә.
Җан-йөрәкнең сафлык, чисталыгын
Саклап тора җырлар бүген дә.

***

*Флера апага*

И зур апа!
Әни урынына калган апа.
Бу нәселнең бөтен йөге хәзер сиңа ята.
Алай дисәң, ул элек тә синдә иде.
Әни мәрхүм сине гел уң кулым дия иде.
Уң булмыйча!
Бүрәнәнең саллы авыр башын
Ныгымаган иңең белән һаман
син ташыштың.
Чыбык-чабык җыеп йөрдең
син урманда,
Унбер генә яшьтә идең ул елларда.
Олы апа!
Өч апаеңны син әйдәп йөрдең,
Барыбызга да оекбашлар
да бәйләп бирдең.
Анысы әле һаман шулай: гомер буе
Синнән киенә бу нәселнең аяк-кулы.
Һаман шулай: балалар да, оныклар да
Син бәйләгән бияләйләр-оекларда
Җылынып үсә. Алар сине Зура, диләр,
«Ярый әле Зура биреп тора», — диләр.
И Зур апа! Барыбызга да Әни апа,
Сәламәт бул, озак яшә әле, Апа!

Киеренке көндә яшибез бит,
Һәм ватылган илдә яшибез.
Күзне сөртергә дә вакытыбыз юк —
Кипсә кибә җилдә яшибез.

Аналар без.
Бала табабыз да
Багар өчен вакыт тапмыйбыз.
Чөнки... «хөрлек» бездә хатын-кызга,
Ирләр белән тигез хакыбыз.

Ә баланы табу гына түгел —
Багу кирәк нәрсә дисәк тә.
Бу дөньяга бала туа ла ул,
Таба аны хәтта ишәк тә.

Кеше тапкан бала кеше булып
Үссен өчен якты дөньяда,
Тана сөте түгел, Ана сөте,
Ана назы кирәк шул аңа.

Ә баланы дөрес карау өчен,
Үз асылы ана кешенең
Затлы булсын иде...
һәм акларлык
Булсын иде Ана исемен.

Безнең чорда җиңел түгел шул ул
Бурычларны үтәү дөньяда.
Чараларын эзләп, чәч агара,
Сәбәпләрен табып, ми яна.

Якты өмет белән тапкан-баккан
Газиз балаң бүген кем була?
Килер буын яшьтән юл югалткан,
Кыйбла юктан иман кыела.

Ыгы-зыгы тормыш, талау, сугыш,
Бөтен нәрсә илдә сатыла.
Сатыла сәгать, сәнгать, сәләт, алтын,
Сатыла хатын... сатыла акыл да.

Иманыңны бөтен саклау өчен
Нишләргә соң? Ничек яшәргә?
Ни тәрбия кылыйк?
Ни калдырыйк
Балаларга бүген, яшьләргә?

Афәтләргә тарган, йортсыз калган,
Балаларын җуйган анага
Кемнәр ничек, нинди ярдәм итсен
Иле-көне шуңа тарганда?

Дәшеп карыйк үзебезнең сүзне,
Әйтми булмый бөтен тавышка;
Ишетсеннәр өстә Ана сүзен:
Чик куйсыннар ялгыш язмышка.

Илгә-көнгә тәртип кайтарылсын,
Хак тәрбия алсын балалар.
Без җаваплы алар бәхете өчен,
Без җаваплы.
Без бит — Аналар.

***

И, бу җирдә һәр мизгелдә
Тулы ямьдә җир йөзе.
Яз чәчәкле, күбәләкле,
Көзе баллы, йөземле.

Яз ташулы — җан ярсулы,
Кыш бураннар туңдыра.
Май аенда сөю туса,
Көзен инде туй була.

Язда салган парлы эзләр
Кышын карга каплана.
...Ничек кайнар сөю хисен
Туйдан соң да сакларга?..

***

Мин элек тә шактый яза идем,
Гонорар да бераз ала идем.
Олау-олау язам бүген дә —
Тик гонорар килми тиен дә.

***

«Юк, моннан соң якын итмим», — дисең,
Якын түгел икән — ерак сана.
Якынлыгың белән бик интектем,
Шайтаныма гына олаксана!

***

Күкләр алланды инде,
Хәерлегә юрап шуны,
Күпләр алданды инде.
Ал төс югалды инде,
Алданганны аңлаганнар
Тагын елады инде.

***

Алтыннардан кыйммәт вакытыңны
Исраф итмә юк-бар эшләргә —
Саран вакыт комсыз гомереңә
Бер минут та тормый өстәргә.

***

Бу тормышта алданулар өчен
Гаепләмә, туган, кемне дә.
Алданулар ахмаклыктан килә,
Ә ахмаклык синең үзеңдә.

Дөрес анысы: алданганың тоеп,
Ышанычны җую бик авыр.
Тик бу дәрес, алда сабак булып,
Ахмаклыктан, бәлки, коткарыр.

***

Җыерчыклар ергалагач
Маңгаеңны, битеңне.
Шуннан кем дә йола алмас —
Картаясың бит инде!

Әмма шуны бирәүдән дә
Ишетәсе килмидер.
«Картлык миңа тия алмас»
Дигән фикер йөри бер.

***

Мин нишләргә белми изаланам,
Кемлегемне белми интегәм.
Бер карасаң, уйлап шигырь язам,
Бер карасаң, җырлап җөй тегәм.

Мин котылу эзлим гөнаһлардан,
Арынырга телим языктан.
Урын тапмый йөрим оҗмахлардан,
Урын тапмый йөрим тәмугтан.

Мин — шагыйрә. Шулай булгач әле
Ник калырга тиеш оҗмахсыз?
Гөнаһларым булса — ялгыш кына,
Ялгышларым булса — гөнаһсыз.

Фани дөнья миңа үзе җәннәт,
Җырлап яшим җирдә шуңа да.
Тәмугына салмасалар бәйләп,
Мин ашыкмыйм оҗмахына да.

***

Ничәнче тапкырлар ышандым да
Ничәнче тапкырлар алдандым.
Ничекләр акыллы үтәргә соң
Бу кыска гомернең калганын?

Шулхәтле катлаулы бу тормышта,
Шушындый алама бу илдә
Яшәүләр авыр да, куркыныч та
Шулкадәр беркатлы күңелгә.

## Белеп бетермисең

Табигать тудырган могҗизаның
Иң даһие — Кеше. Аның да
Капма-каршы җитмеш җиде ягы
Тарткалашып тора җанында.

Шул иң камил дигән зат үзендә
Аек акыл белән беррәттән
Исәр хисләр өереннән торган
Юләрлекне мәңге ияртkән.

Шул бер затта күпме итагатьлек
Сары алтын дигән сабырлык!
Янәшәдә күпме дуамаллык,
Чик-чаманы белмәс явызлык!

Карбыз түгел — ярып карап булмый,
Кавын түгел, иснәп танырга.
Иң камил зат — Кеше, тик кемлеген
Белеп бетермисең аның да.

***

Мин бик куркам сине яратудан,
Бу — хисләрнең инде соңгы гына.
...Һәм мин куркам синең җавабыңнан —
Мин ышанмыйм аның чынлыгына.

Бу — хисләрнең инде соңгы гына,
Әрнеттереп яра сала торган.
Килер таң юк, таңнар узган, шуңа
Мин бик куркам сине яратудан.

Болар соңгы тартылышы сыман
Саташулы җанның җыры гына...
Мин бик куркам синең җавабыңнан,
Мин ышанмыйм аның чынлыгына.

***

Көне-төне сине эзли күңел,
Көне-төне уйлый бу башым.
Син югында янда якты түгел
Төнлә аем, көндез кояшым.

Көне-төне сине тели җаным,
Көне-төне сине сагынам.
Ямен күрмим синсез бу дөньяның,
Бер көнгә дә китмә янымнан!

Көне-төне сине көтә йөрәк,
Көне-төне тик син уемда.
Көне-төне миңа бер син кирәк,
Көне-төне... гомер буена.

***

Күк күкрәүдән җаның тетрәнмәсен,
Ул — яшеннең бары тавышы.
Яшен үзе сукмый үткән икән,
Куркынычлы түгел анысы.

Җир тетрәсә — җаның әзер булсын —
Убылуы мөмкин нигезең.
Ычкынуы мөмкин ул җаныңның
Гөнаһлары белән бу җирнең.

Кеше булып килгән бу дөньядан
Аерылыр көнең килгәндә,
Кеше булыр өчен, эчкерсез бул
Дус белән дә, дошман белән дә.

***

Мин элекке гашыйк түгел инде,
Шаккатыра торган дөньяны.
Яшьлек язым күптән китте инде,
Гомер җәем сүнде, югалды.

Китеп бара әнә саргылт көзем,
Кереп килә кышка гомерем.
Тик әйтмәгән әле соңгы сүзен,
Сөю сүзен җырлы күңелем.

Язларда мин күпме яр яраттым,
Җәйләрдә дә яндым, яшермим.
Алай гына сөяр идемме әле,
Кире кайтса әгәр яшьлегем?!

Барлык җиргә, бөтен эшләргә дә
Өлгерергә кирәк.
Мәктәпләргә, китапханәләргә
Йөгерергә кирәк.

Кибетләргә, шифаханәләргә
Күз салырга кирәк.
Мәчетләргә, музейларына да
Гел барырга кирәк.

«Җомга» өчен татар телен белгән
Зат табарга кирәк.
...Кер юарга, аш-су әзерләргә
Һәм... язарга кирәк.

И Ходаем!
Өйрәт, күрсәт миңа
Берәр тылсым көчен.
Терекөмеш булу кирәк миңа
Болай яшәү өчен.

***

Сукмакларга сары keләм түшәп,
Каен яфрак коя.
Яфрак коеп көзге җилләр иссә,
Җаным сыкрап куя.

Яфрак коеп көзге җилләр иссә,
Туйлар чоры керер.
Көзләр җитсә, авыл бәйрәм көтә,
Туйлар көтә кемдер.

Көзләр җитсә, авыл бәйрәм көтә,
Туен көтә бар кыз.

Пары белән бар да, яры белән —
Бер мин генә ялгыз.

Пары белән бары, яры белән...
Туйлар көзләр җитсә...
Сукмакларга сары яфрак түгеп,
Көзге җилләр исә.

Каеннардан сары яфрак төште,
Өзгәләнә күңел...
Җан яраткан, күңел тарткан кешем
Үземнеке түгел,
Үземнеке түгел.
Ах, минеке түгел,
Үземнеке түгел...

***

Берни бирми, гомер үтеп бара,
Яшәешем узгын уен гына.
Уйнап кына чынлап чәч агара,
Картаела. Үзем тоймыйм гына.

Яшәешем узгын уен гына,
Уйныйм эштә, уйныйм гаиләдә.
Илаһи бер терәк — җырым гына,
Илһам шәме җирдә, гади мәлдә.

Уйнап кына чынлап чәч агара,
Буяу күмми хәтта аклыкларын.
Җилгә очмый, шуңа сеңеп кала
Кичерелгән кайгы-шатлыкларым.

Картаела. Үзем тоймыйм гына.
(Бу дөньядан тоймый китеп кара.)
Тоймыйм диюем дә уен гына —
Берни алмый, гомер үтеп бара.

## Муниципаль университет студентларына юллама сүз

Беләге юан берне егар,
Меңнәрне җиңәр белемле булган.
Әлмәттә туган бу уку йорты
Сезне белемле итәргә туган.

Татарстанның нефть төбәге
Башкаласында уку йортыгыз.
Ул илгә кирәк белемне бирер,
Кадерен генә белеп укыгыз.

Яшьлек алдында сынаулы юллар,
Сират күперен белемле чыгар.
Беләге юан берләрне җиңәр,
Белеме булган меңнәрне егар.

Ә Сезгә белем киләчәк көнне
Яктыртыр өчен, яшәртер өчен.
Җилгә туздырмый, бушка уздырмый,
Эшкә бирегез Яшьлекнең көчен.

***

Элек-элек төрки кабиләләр
Яшәгәндә чатыр-тирмәдә,
«Һай, бер генә чыгып күренсә!» — дип,
Син йөргәнсең минем тирәдә.

Ә аннан соң Болгар калалары
Гөрләп чәчәк аткан заманда,
«Күрмәмме?» — дип, манарага килеп,
Син бит йөрдең зарыгып һаман да.

Аннан соң да, Казан ханлыгында
Сәүдә-базар гөжләр чакларда,
Күләгәмне күзләп, күрешү эзләп
Килә идең акбүз атларда.

Бәйсезлегең хәтта бәйле чакта,
Тубыгыңнан баткан урында
Син дастаннар яздың минем хакта,
Җыр чыгардың минем турында.

Бүген мине тупас рәнҗетәсең.
Бу гадәткә нәрсә өйрәтте?
Хатын-кызны санга сукмас итеп,
Татар җанын нәрсә үзгәртте?

Сәбәп, бәлки, минем үземдәдер?
(Икеләтә авыр, каты сүз.)
Безнең көндә сөю-сөелүгә
Лаек түгел, димәк, хатын-кыз...

***

Мәңгелектә күпме җинаять,
Мәңгелектә күпме хыянәт! —
Синең гомер җирдә бер мизгел.
Ул мизгел дә олы языктан,
Гөнаһлардан һич азат түгел.

Кыска гына шушы гомердә
Күпме хата кылдың бу җирдә!
Тәүбә китер, үкен-үкенмә —
Шул көенчә керерсең гүргә.

«Бөкерене кабер төзәтә», —
Дисәләр дә, белмим, икеле.
Турайמаган әнә үлгәч тә,
Табутта да шайтан бөкере.

***

Ул чакларда син гел бүтән идең.
Итәк җилең килеп тиюдән,
Фәрештәләр азып җиргә инде,
Бөтен диндар язды дененнән.

Барысы да, нидер өмет итеп,
Өерелеп йөрде артыңнан.
Тота алмадылар.
Кемне көтеп
Кире кага килдең барсын да?

Бүген нәрсә?
Сүзсез буйсынасың
Ымлавына надан берәүнең.
Гаҗәпләнәм: син соң үзеңдәге
Сихри көчне кая җирләдең?

...Яшь чакларда син гел башка идең,
Охшамаган идең бүгенгә...
Моңсу булып китте
курка-курка
Сине сөеп йөргән күңелгә.

***

*Альмирага*

Бу елмаю синең өйне
Җәннәт ясый бугай.
Бар җәннәтне саклап торган
Түбә агачыдай.

Җылы, нурлы бүлмәләрең,
Якты йөзле үзең.
Мине шундук әсир итте
Елмаюлы йөзең.

Өстәлеңдә кайнар чәең,
Ачык, якты чырай.
Бар җәннәтне төреп торган
Түбә агачыдай.

***

Чын дөресе шушы: бу заманда
Кырыктан соң ир-ат җегәр көчен
Ярын яратуга караганда
Күбрәк бирә сакал кырыр өчен.

Ә хатын кыз?..
Аның язмышы шул:
(Ачып сала аны шушы дүрт юл!)
Ул кияүгә чыга гомер ялгыз үтмәсен, дип,
Аннан түзә кеше гаеп итмәсен, дип,
Аннан тора балам ятим үсмәсен, дип.
Инде яши олыгайдым, нишләтим? дип.

Менә шул.

***

Әлли-бәлли, бәүкәем,
Йокла инде, бәбкәем.
Йоклар вакыт бит инде,
Син дә йоклап кит инде.

Йокла, тәмле төшләр күр,
Нәвем базарына кер.
Мин дә шунда барырмын,
Тәти күлмәк алырмын.

...«Алдыйсың!» — дип, әбигә
Үпкәләмә, и бала!
Хәзер тәти күлмәкне ул
Төштә генә алала...

***

Күктә кояш сиңа көндәш түгел,
Ай-йолдызлар сиңа тиң түгел.
Син бик чибәр, әмма синең алда
Тез чүгүче мәхлук мин түгел.

Матур йөзең, шомырт кара күзең,
Кыйгач кашың җырга теркәрлек.
Буең-сының зифа, киемнәрең
Күргәзмәдә үрнәк итәрлек.

Тыштан чибәр, әмма эчке дөньяң?
Анда бушлык, гамьсез салкынлык,
Битарафлык, тагын әллә нәрсә,
Тик юк анда эчке матурлык.

Ташкурчактай матур чыраеңнан
Күзгә бәрә төпсез буш күңел.
Әйе, андый күңел иясенә
Табынучы кеше мин түгел.

Сезнең дә бар күркәгез,
Безнең дә бар күркәбез,
Күршеләрнең тавыкларын
Күркә итеп йөртмәгез.

Сезнең дә бар казыгыз,
Безнең дә бар казыбыз,
Безнең казлар ысылдаса,
Тыяр чара табыгыз.

Сезнең дә бар күршегез,
Безнең дә бар күршебез,
Күршеләр нинди булсалар,
Без дә шулар төслебез.

Сезнең дә бар өегез,
Безнең дә бар өебез,
Сезнең өйдә үз көегез,
Бездә дә үз көебез.

***

Тагын киттең.
Ярый киттең,
Ярый киттең берүзең,
Ярый мине алмый киттең,
Җитә иде бер сүзең.

Сыңар сүзең җитә иде,
Ым кагуың «әйдә!» дип...
Ияргән булсам, ничек кире
Кайтыр идем әйләнеп?

Ярый киттең.

***

Сыңар чәчәк бирде берәү миңа
Һәм елмайды шундый киң итеп.
Шул чәчәкне тотып кайтып киләм,
Дөнья бәясенә тиң итеп.

***

Күз яшьләрен йотып көлеп йөрдем,
Көлке аша сыкрап еладым.
Юклык кысып, тыным өзелгәндә,
Мин җилбәзәк булып уйнадым.

Фәкыйрьлектән җаным көйде минем,
Мондый хәлгә беркем чыдамый...
Моңа кадәр күпме түзеп килдем,
Әрнүләрне тышка чыгармый.

Түземлегем бетте, чигенә җитте.
Шундый хәлдә менә мин хәзер:
Гүя әрнү, күкрәгемнән чыгып,
Шәүлегәндәй шыңшып җибәрер.

Кирәкми лә!..
Юк, юк!
Кирәкми лә!..
Кара көчне шыңшып кем җиңгән?
Бер мин генәмени кабих илдә
Эт тибенкесендә тилмергән?..

***

Җәйге көндә тәрәз ачсаң —
Күз күреме яшел җәй.
Пыялада кояш нуры
Елык-елык яшендәй.

Ә кыш көне иксез-чиксез
Аклык кая карама.
Тәрәзәдәге пыялада
Абагалар агара.

Әкият урманнарының
Чагылышы пыяла.
Мәңге кысыр абагалар
Чәчәк ата хыялда.

Тик кышын барлыкка килгән
Манзарада шау урман.
Шуңа карап: «Никләр соң мин
Рәссам түгел?» — дип торам.

Сүзгә сыймас бер байлык бит,
Телгә сыймас гүзәллек.
Илаһи бу күренешне
Бәяләргә өйрәник.

***

Кошлар китте. Кышка калган
Ала каргалар гына
Нидер ташый әле һаман
Тузгак ояларына.

Ала карга монда кала,
Китеп бара карасы.
Киткәннәнме, калганнанмы? —
Кемнән үрнәк аласы?

Язын килгән кара карга
Күзен кая юл тота?..
...Монда калган ала карга
Кышка оя ныгыта.

***

Әй, бормалы тау сукмагы!
Мине,
Алдап-юлдап, кая чакырасың?
Борма юллар кире бормас иде,
Белсәм аның кетеп торасын.

Борма юллар кире бормас иде,
Таулардан да, диңгезләрдән дә...
Очрашулар булса булыр инде
Борма юллар тигезләнгәндә.

Очрашулар булса булыр иде
Икебез дә киткәч, җирләнгәч...
Син оҗмахта, Изге. Әмма мине
Гөнаһларым анда җибәрмәс.

Кавышулар насыйп түгел инде,
Сак-Сок язмышлары анда да...
Әй, бормалы тау сукмагы, мине
Ул көтә дип анда алдама...

***

Күңелдәге серне-сөюемне
Тыя алмас булсам әгәр дә,
Кулым белән түгел, җырым белән
Кагылырмын синең тәрәзгә.

Кабул итү-итмәү синең эшең,
Тик ишетсә күңел колагың,
Кире кага алмас сөю хисен,
Сиңа илткән йөрәк җырларын.

Яраттырыр тылсым серен беләм,
Коралы җыр сөю хисенең.
Кулым белән түгел, җырым белән
Мин ачармын күңелең ишеген.

***

Күрәчәкнең барын күрдек бугай,
Шулай киләм синең каршыңа.
Тәкъдирдә ни язган булса Ходай,
Кичерергә кирәк барсын да.

Үргә күтәрелгән чоры да бар,
Түбән төшкән чак та онытылмый.
Онытылган очсыз җыры да бар,
Кыйммәтлесе дә бар.
Ул тынмый.

Кыйммәтлесе сөзелеп яшәп кала.
Шундый җырым кала,
һәм шуңа
Мин ашыкмыйм әле сиңа таба,
Соңлабрак, үлем, каршыла.
Ашыктырма мине.

***

Син кайларда, күрәзәче кәккүк?
Син кайларда бүген, ялганчы?
«Аның әле яшәр яше күп», — дип,
Җәйләр саен безне алдаучы.

«Аның әле яшәр яше күп», — дип,
Син узган җәй генә сиксәнне
Санап киттек.
Әмма гомере бит
Утызга да тулып җитмәде.

Япь-яшь килеш кара гүргә керде,
Ятим итеп ике баласын.
Яман чирдән йолып калыр дәва
Безнең тыйб кайчан таба соң?

Изге ялган гына булган икән
Сиксән яшьлек гомер юравың.
Син кайларда, и ялганчы кәккүк?
Ник җавапсыз кала соравым?

# Зөбәрҗәт

*Бөек Ватан сугышының 50 еллыгына*

*(Поэма)*

«Әйдә, күк ат, безне озат,
Үрләрне меңгерерсең...
Сагынырсың, саргаерсың,
Күрергә тилмерерсең!»

Зәки җырлый. Күк атына
Атап дәшкән булса да,
Кинәсе бар: атка түгел,
Зөбәрҗәткә сүз сала.

Сүз салганда, сер салганда,
Кире какты Зөбәрҗәт,
Яратмаудан түгел иде —
Бик яратты Зөбәрҗәт.

Бик яратты, яшьлек яңа
Канат каккан чак иде,
Тик... мәктәпнең соңгы елын
Тәмамлыйсы бар иде.

Аннан соң хыял-планнар
Якты, өметле иде.
Афәтле сугыш килде дә
Дәртле өметне өзде.

Сабантуйда кайгы туе
Бәреп керде өйләргә.
«Әйдә, күк ат, безне озат!»
Киттеләр Зәкиләр дә...

Китте яшьләр берәмләп тә,
Дистәләп тә, йөзәрләп.
Зәки хаклы: сагынды да,
Саргайды да Зөбәрҗәт.

Саргайды да, каралды да,
Агарды да йөзләре.
Салкын көздә, кара кышта
Район юлын өзмәде.

Үрләр менеп, Зәкиләрне
Озата барган атларда
Почта йөртте. Алып кайтты
«Отьявка»лы хатлар да...

...Киткәне бар, калганы бар...
Кайтканы да бар тагын.
Зиннәт кайтты, сул кулының
Өздереп өч бармагын.

Ә Зәкидән хат-хәбәр юк,
Әмма авыл телендә
Зиннәт салган хәбәр йөри,
Калган, диләр, пленда.

Зиннәт үзе күргән, имеш,
Кул күтәреп бирелгән.
Зөбәрҗәтнең күз аллары
Томаланды бу сүздән.

Чынлап тамы?! Булмастайны
Хак булса да сөйләмә!
Зәки булып Зәки шулай?..
Ил таяныр кемнәргә?!

Юк, ышанмыйм! Мөмкин түгел!
Кара яла бу, гайбәт!
Зиннәт белән күрешер көнне
Шулай диде Зөбәрҗәт.

Шулай диде, әмма үзе
Мендәренә яшь түкте.
«Зәки, Зәки! Синме саттың
Мине, Илне, Яшьлекне?!»

Әгәр шушы дөрес булса?
Мөмкин түгел, юк, булмас.
Зөбәрҗәтнең күңелендә
Андый кара шик тормас.

Ул Зәкинең җан-күңелен
Үтәли күрә иде.
Бергә туып үсте алар,
Көннәре бергә иде.

Бер тыкрыкта тордылар,
Капкалар да янәшә.
Бер класста укыдылар,
Парталар да янәшә.

Мәктәпкә дә бергә барып,
Бергә кайтып йөрделәр.
«Кияү-кәләш» исемен дә
Балачактан бирделәр.

Балачактан саф йөрәктән
Үз итте берсе-берсен.
...Әйдә, күк ат, безне озат,
Урләрне меңгерерсең...

Әйдә, күк ат! Күпмеләрнең
Күзе почта юлында.
Атның хәзер агы, күге
Хатын-кызлар кулында.

Зөбәрҗәттә почта аты.
Һәм көннәрнең берендә
Ул «отьявка» алып кайтты
Зәкиләре өенә.

Өч кенә юл: «Батырларча
Һәлак булды улыгыз!»
«Газиз бала!..»
Ата-ана!
Зинһар, сабыр булыгыз!

Башкайларны авыр кайгы
Идерсә дә, түзегез.
Шул корбаннар хакы белән
Җиңү яулый Илебез.

Авыр кайгы, әмма аны
Күтәрербез бергәләп...
«Мин — кызыгыз, киленегез
булам», — диде Зөбәрҗәт.

Колаклары ишеткәнне
Аңлый алмый карт ата.
«Нинди килен? Каян килен?
Ничек?» — диеп баш вата.

Аптыраудан, гаҗиз калган
Анасы да Зәкинең.
Асылында ни сәбәп соң
Болай дип әйтүнең?

Бәнат апа улы белән
Зөбәрҗәтнең дуслыгын
Белә иде һәм бәхетле
Саный иде үз улын.

«Әйбәт кенә йөрсеннәр дә
Бергә тормыш корсыннар».
Күңеленнән күпме дога
Юллагандыр ул шуңар.

Әмма бүген аптыраулы
Һәм сораулы күңеле.
Малае юк йортка ничек
Төшсен юньле килене?

Андый-мондый хәл булса да
Яшьләрнең арасында,
Инде Зәки киткәнгә дә
Ике ел ара сыман...

«И Ходаем! Тьфү, тьфү!
Әллә башка берәүнең
Гөнаһынмы безгә яга?..» —
Дип пошына йөрәге.

Алай дисәң, Раббем! Аллам!
Булмаганны! Кит аннан!..
Инсафлылык, саф яктылык
Бөркеп тора бит аннан.

Әнә килде. Кулын бирде.
«Әнкәй!» — диде өзелеп.
Раббем! Аллам! Изге ялган.
Бир сабырлык, түземлек.

Күзләренә яшь чыгарма,
Калтыратма тавышын.
«Ялган белән ялгап алам
Сугыш толы язмышын...»

— Әнкәй! — диде, —
Зәки үлгән.
Сез дә ятим, мин дә тол.
Никахлашып өлгермәдек —
Минем ирем иде ул...

...Килен шулай килеп керде,
Бөтен авыл таң калды.
Һәм Зөбәрҗәт гомере буе
Ташламады картларны.

Инде күптән каенана да,
Каената да кабердә.
Йорт-нигездә ялган килен
Ялгыз яши хәзер дә.

Ел да авыл яз — бер, көз — бер
Җырлап солдат озата.
Өзелә күңел, сызыла күңел,
Яшь түгә күз шул чакта.

Түгелмә, яшь, кайгырма, баш!
Без күрәсен кем күрсен?!
...Әйдә, күк ат, безне озат,
Үрләрне меңгерерсең...

## I. Кояш инде китеп бара иде

Юл ачык та — еллар ябык . . . . . . . . . . . . . . 4
Төс ташлады бу җир . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Үзгәлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
«Йә әле, җылын, — дисең...» . . . . . . . . . . . . . 6
«Ник тәрәзә капкачларын...» . . . . . . . . . . . . . 6
«Без дә юкәдән түгел...» . . . . . . . . . . . . . . . . 7
«Булмаганны!..» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
«Тынгысызлый нигә һаман шулай...» . . . . . . . 8
«Ә мин әле һаман сине көтәм...» . . . . . . . . . . 8
«Тезгә түнми тора гәүдәм генә...» . . . . . . . . . 9
«Бернәрсә дә юктан тормый...» . . . . . . . . . . . 9
«Бер нәрсәдән курка күңел...» . . . . . . . . . . . 10
«Тынлыгы белән шомлы төн...» . . . . . . . . . . . 11
«Бер ай гына йөреп калдык...» . . . . . . . . . . . 11
«Син үлчәүсез мескенлектә бүген...» . . . . . . . 12
«Үләсе калган яшь килеш...» . . . . . . . . . . . . 13
«Кояш инде китеп бара иде...» . . . . . . . . . . . 14
1999 . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
«Синнән соң да, әни, ун ел үткән...» . . . . . . . 15
«Тирән иде хыял дәрьяларым...» . . . . . . . . . . 16
«Минем һаман яратасым килә...» . . . . . . . . . . 16
«Тәнәкә — Шагыйрь җанының...» . . . . . . . . . . 17
«Тышта ап-ак кар ява...» . . . . . . . . . . . . . . . 18
«Үз шигырен үзе укый икән...» . . . . . . . . . . . 19
«Сәясәтче дә түгел мин...» . . . . . . . . . . . . . . 19
«Унҗиденче гыйнвар...» . . . . . . . . . . . . . . . . 20
«Ходай сине минем өчен...» . . . . . . . . . . . . . . 21
«Тәңре кушуын тыңлыйм, каршы дәшмим...» 22
«Интектерә, белмим, нидер...» . . . . . . . . . . . . 22
«Августның да ундүрте бит инде...» . . . . . . . . 23
«Унбиш минутта ни эшләп була?..» . . . . . . . . 24
«Камышлар шуылдаша да...» . . . . . . . . . . . . . 24
«Бу елда соңга калган көзнең...» . . . . . . . . . 25
«Кошлар монда әле, күченмәгән...» . . . . . . . . 25

«Әгәр ирең...» .......................... 26
«Хәзер кайда эшләсәң дә...» .......................... 26
«Сусаганда, кое казы...» .......................... 27
«Кайсы әйткән...» .......................... 27
«Сусыз, күлсез иде безнең яклар...» .......................... 28
«Тәрәзәдә беренче боз бизәк...» .......................... 28
«Өзелмәс тә өзмәс бер моң килә...» .......................... 29
«Бүгенге көн чуар...» .......................... 30
«Бәхет — хезмәт!...» .......................... 30
«Бүтән килмә минем яныма син...» .......................... 31
«Менә шушы кара сазлар аша...» .......................... 32
«Яфраклар очты, очты да...» .......................... 32
«Сиңа унҗиде генә яшь...» .......................... 33
«Ноябрьнең унҗидесе...» .......................... 35
«Әлмәтебезнең туган көнендә...» .......................... 36
«Яннарымда бары син барында...» .......................... 39
«Җаннарыма кайчак кара кайгы куна...» .......................... 39
«Акка күчерәсе нәрсәләр күп...» .......................... 40
«Болыннарда нур булганда...» .......................... 41
«Ботакны сарган сыкылар...» .......................... 42
Яңа елга керәм, дигәндә... .......................... 42
«Гыйльмениса карчык шәлләр бәйли...» .......................... 43
«Яңа елда кайдадыр...» .......................... 44
«Алтын арыш басуын...» .......................... 45
«Мин бу җирдә озак яши алмам...» .......................... 46
Капыл туган җыр .......................... 47
«Кемдер әлләниләр көтәдер дә...» .......................... 48
«Гасырның соңгы елында...» .......................... 48
«Яңа елга сәгать ярым...» .......................... 50
«Һай, авыр, авыр, авырта...» .......................... 51
«Яшәгән чакта бу җирдә...» .......................... 51
Бер хатирә .......................... 52
«Елак димәс мине белгән кеше...» .......................... 54
«Ерып чыга алмас болгавыр чор...» .......................... 54
«Халык әйтсә, әйтер хагын...» .......................... 55
Авыл көндәлегеннән җәйге язмалар .......................... 56
«Ялгыш көндәлегем ачтым...» .......................... 57
«Ундүртенче июль көне...» .......................... 57
«Питрау атнасының шушы көннәрендә...» .......................... 58

«Элекке хәтерең туңган...» . . . . . . . . . . . . . . . . 59
«Ә бу дөнья инде кая бара?..» . . . . . . . . . . . . . . 60

## II. Фани дөньяда да Иман кирәк

«Мидә «зең-зең» шигъри кыллар зеңли...» . . . . 62
«Еллар-сулар ага, ага, ага...» . . . . . . . . . . . . . . . 62
«Бу йөрәк тынгылык ник белми соң?» . . . . . . . 63
«Әвәләде дөнья кемне таштан...» . . . . . . . . . . . 63
«Аерылышты... уйлар...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
«Җиденче кат күккә менәр кебек...» . . . . . . . . . 64
«Чыгарабыз диеп җирнең маен...» . . . . . . . . . . . 65
«Яңача майның уртасы...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 65
«Ни булды соң әле сиңа, авыл?..» . . . . . . . . . . . 66
«Җитмеш ел элгәре кебек...» . . . . . . . . . . . . . . . 67
«Ниләр генә кылып яшәмәдең...» . . . . . . . . . . . 68
«Күпме генә яшәдем соң?..» . . . . . . . . . . . . . . . 68
«Әгәр тормыш сине алдый икән...» . . . . . . . . . . 69
Туган җиремә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69
«Минем гомер минутларын...» . . . . . . . . . . . . . 70
«Гел былтыргы Яңа елдагыча...» . . . . . . . . . . . . 70
«Тигез генә, туры гына түгел...» . . . . . . . . . . . . 71
«Мин, мөгаен, татар хатыныдыр...» . . . . . . . . . . 71
«Ямь арттырып дөньяга...» . . . . . . . . . . . . . . . . 72
«Нинди нур ул?..» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73
«Мин — шагыйрә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73
«Кичтән чыгып...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74
«Кул салынган, хәрәкәтсез...» . . . . . . . . . . . . . . 74
«Бу җырларда бернинди дә яңалык юк...» . . . . 75
«Үзең теләгәнчә булсын әйдә!..» . . . . . . . . . . . . 76
«Син кил генә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
«Сез барыбер мине аңламассыз...» . . . . . . . . . . 77
«Затсыз тәнем йөри ил каршында...» . . . . . . . . . 77
«Әллә кайда, еракдагы...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
«Кагылынмаган яшьлегем...» . . . . . . . . . . . . . . . 78
«Күрсәм дә күзләрендәге...» . . . . . . . . . . . . . . . 78
«Явыз яз харап иткәндәй...» . . . . . . . . . . . . . . . . 79
«Хатларыңны саклыйм...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 79
«Минем сөю ак болыттай...» . . . . . . . . . . . . . . . . 80

«Кемдер карый кемнәр күзенәдер...» .................. 80
«Без, хатын-кыз...» .................. 81
«Сылу таллар. Нишли алар...» .................. 81
«Бәгырем, иркәм, дигән...» .................. 82
«Аккошым», — диделәр...» .................. 82
«Таңнарның чыклысын...» .................. 83
«Язлардан алда җанны җилкеткән...» .................. 84
«Урамнарда кояш...» .................. 84
«Ничә ел аша бу күңел...» .................. 85
«Күптән инде хатлар килми миңа...» .................. 85
«Әллә нинди югалтулар белән...» .................. 86
«Синдә үтте минем нинди еллар!..» .................. 86
«Син киткән көздән соң...» .................. 87
Афәт .................. 87
«Уңган, булган хатын белән...» .................. 88
«Һәр кешегә аерым бер бүлмә...» .................. 88
«Үткәннәре уртак булды...» .................. 89
«Сабый чагым...» .................. 89
«Киләчәк көн турында да...» .................. 90
«Мин хыялда гына җыйган байлык...» .................. 91
«Үлемнән дә курыкмаска кирәк...» .................. 92
«Соң минутта кемгә караш салыр...» .................. 92
«Сагышларга башны салмыйк әле...» .................. 92
«И Шигырем!..» .................. 93
«Үтә биелгы кышлар да...» .................. 93
«Күзгә төшкән кояш нурлары да...» .................. 94
«Бу чияләр шау чәчәктә иде...» .................. 95
«Карт башына яткан кар аклыгы...» .................. 95
«Сарман юлларында сары чәчәк...» .................. 96
Әлмәт. Рәсемнәр күргәзмә залында .................. 96
Дуамал җыр .................. 97
Бер генә .................. 97
«Улым утлы борчулы бу араларда...» .................. 98
«Ул колхозның бригадиры иде...» .................. 99
«Атнага бер генә...» .................. 100
«Күзәткәндә тау бөркете очышын...» .................. 101
Хәтер тәрәзәләре .................. 101
«Бик биектә тургай...» .................. 103
Оныта алмассың... .................. 104

Өйрәтегез! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
Яз җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105
«Бүтәндер ул...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 106
«Зәңгәр күкләр, ак болытлар...» . . . . . . . . . . 106
Син генә юк чия бакчасында... . . . . . . . . . . . 107
Инде берүк чайпалмасын . . . . . . . . . . . . . . 107
Әрнүле җыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108
Адәм баласыннан ни сорала? . . . . . . . . . . . 109
«Ә тормыш бик авыр...» . . . . . . . . . . . . . . . 109
«Абынып егылабыз да...» . . . . . . . . . . . . . . 110
«Ышансаң-ышанмасаң да...» . . . . . . . . . . . . 110
«Аклы яулык, ак бөрчеккәй яулык...» . . . . . . . 111
«Юлларның чаты да...» . . . . . . . . . . . . . . . 112
«Башы-соңы бергә төйнәленгән...» . . . . . . . . 112
«Кем кемгә бүген илтәдер...» . . . . . . . . . . . 113
«Тулар-тулмас сыңар гомеремдә...» . . . . . . . . 113
«Син кузгатма инде тынган җанны...» . . . . . . . 113
Соң булса да... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 114
Игенче җаны . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 114
«Яз айлары җиргә тагын килер...» . . . . . . . . 115
Исемсез җыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 115
Күңел күкләремдә болыт ята . . . . . . . . . . . . 116
Нәүрүз җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117
«И, и генә, и ил генә дидек...» . . . . . . . . . . 118
Ком сәгате . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 118
«Ярый әле җырым тына белми!..» . . . . . . . . . 119
Май башлары... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
И Алла... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120
«Без барыбер бер күрешербез әле...» . . . . . . . 121
Яшәештән берүк йөз чөермә! . . . . . . . . . . . 121
Нократ-Елга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
Сөю турында янә бер җыр . . . . . . . . . . . . . 123
«Яр буена төшкән борма сукмакта...» . . . . . . . 124
«Үз өеңә кайтып үлде улың...» . . . . . . . . . . 124
«Барла, әйдә, фәкыйрь байлыгыңны...» . . . . . . 124
«Яшь чагында күңел иркен булган...» . . . . . . . 125
«Җирдә яши адәм балалары...» . . . . . . . . . . 125
«И зур апа!..» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126

Без җаваплы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127
«И, бу җирдә һәр мизгелдә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 129
«Мин элек тә шактый яза идем...» . . . . . . . . . . . . . . 129
«Юк, моннан соң якын итмим...» . . . . . . . . . . . . . . . 129
«Күкләр алланды инде...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 130
«Алтыннардан кыйммәт вакытыңны...» . . . . . . . . . . 130
«Бу тормышта алданулар өчен...» . . . . . . . . . . . . . . 130
«Җыерчыклар ергалагач...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 131
«Мин нишләргә белми изаланам...» . . . . . . . . . . . . . 131
«Ничәнче тапкырлар ышандым да...» . . . . . . . . . . . . 132
Белеп бетермисең . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132
«Мин бик куркам сине яратудан...» . . . . . . . . . . . . . 133
«Көне-төне сине эзли күңел...» . . . . . . . . . . . . . . . . 133
«Күк күкрәүдән жаның тетрәнмәсен...» . . . . . . . . . . 134
«Мин элекке гашыйк түгел инде...» . . . . . . . . . . . . . 134
Терекөмеш булу кирәк миңа . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
«Сукмакларга сары келәм түшәп...» . . . . . . . . . . . . . 135
«Берни бирми, гомер үтеп бара...» . . . . . . . . . . . . . 136
Муниципаль университет студентларына юллама сүз 137
«Элек-элек төрки кабиләләр...» . . . . . . . . . . . . . . . . 137
«Мәңгелектә күпме җинаять...» . . . . . . . . . . . . . . . . 138
«Ул чакларда син гел бүтән идең...» . . . . . . . . . . . . 139
«Бу елмаю синең өйне...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 140
«Чын дөресе шушы: бу заманда...» . . . . . . . . . . . . . 140
«Әлли-бәлли, бәүкәем...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 141
«Күктә кояш сиңа көндәш түгел...» . . . . . . . . . . . . . 141
Шаян такмаклар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 142
«Тагын киттең. Ярый киттең...» . . . . . . . . . . . . . . . . 142
«Сыңар чәчәк бирде берәү миңа...» . . . . . . . . . . . . . 143
«Күз яшьләрен йотып көлеп йөрдем...» . . . . . . . . . . 143
«Җәйге көндә тәрәз ачсаң...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 144
«Кошлар китте. Кышка калган...» . . . . . . . . . . . . . . 144
«Әй, бормалы тау сукмагы!..» . . . . . . . . . . . . . . . . . 145
«Күңелдәге серне-сөюемне...» . . . . . . . . . . . . . . . . 146
«Күрәчәкнең барын күрдек бугай...» . . . . . . . . . . . . 146
«Син кайларда, күрәзәче кәккүк?..» . . . . . . . . . . . . 147

Зөбәрҗәт. *Поэма* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148

Литературно-художественное издание

**Клара Булатова**

(Булатова-Рафигуллина Клара Гарифовна)

*Боль*

Стихи

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *Й.М.Вәлиәхмәтов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире, компьютерда биткә салучысы *Н.П.Клипова*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия
2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал макеттан басарга кул куелды 22.07.2003.
Форматы $70 \times 90^{1}/_{32}$. Офсет кәгазе. «Антиква» гарнитурасы.
Шартлы басма табагы 5,85+форз. 0,15. Шартлы буяу оттиск 6,73.
Нәшер-хисап табагы 5,74+форз. 0,24.
Тираж 2000. Заказ Я-474.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru E-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе. 420066. Казан, Декабристлар ур., 2.